КЫРЫН ЭШ

Мошенниклар халыкны төп башына утыртуның яңа юлларын уйлап тапкан

> 5

МОГҖИЗА КӨТКӘНДӘ

2021 елдан 2023 елга кадәр россиялеләрнең эзотерика белән кызыксынуы өч тапкыр диярлек арткан

> 7

АЙДАР ФӘЙЗРАХМАНОВ:

«Сәнгатьне боза да, сыза да, юкка чыгара да алалар»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 158 (29125) | Җомга | 27 октябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ДӨРЕС ЮЛ

БАЛТАЧ РАЙОНЫНДА ЯШӘҮЧЕ 10 БАЛА ӘНИСЕ НАИЛӘ ГАЛИЕВА «ГЕРОЙ АНА» ИСЕМЕНӘ ЛАЕК БУЛДЫ

Президент Владимир Путин алты хатын-кызга «Герой ана» исеме бирде. Әле бу атнада гына имзаланган Указда Балтач районының Кариле авылында яшәүче 70 яшьлек Наилә Галиеваның исеме дә бар. Наилә апа гомер бүләк иткән 10 баланың тугызы (!) авылда төпләнеп калган. Сөенечен уртаклашып, аның белән игелекле балалар тәрбияләү, гаилә кыйммәтләрен саклау, туган нигез кадере турында сөйләштек.

> 17

Ишетми калмагыз

Ноябрьдән кайберәүләрнең пенсиясе артачак. Иң элек узган айда 80 яшен тутыручылар саллы гына өстәмә ала башлаячак: пенсияләренең төп өлеше (7567,34 сум) ике тапкыр артып, 15134,66 сумга җитәчәк. «Прайм» хәбәренә караганда, элекке очучылар һәм шахтерларны да өстәмә көтә. Аның күләме хезмәт хакына һәм оешмаларының Социаль фондка күпме акча кертүләренә бәйле. Узган елларда шахтерларга өстәмә күләме 3,5 меңнән 5,5 мең сумга кадәр тәшкил иткән.
Моннан тыш «Төньяк стажы»на ия булучылар пенсиясенең төп өлешен, кайсы территориядә эшләгәннәренә карап, 30–50 процентка арттырырга җыеналар. Өстәмә күләме башка төбәккә күченгәнгә карап үзгәрми.

Илкүләм «Алдынгылар хәрәкәте»нең Татарстандагы бүлеге 1 меңгә якын башлангыч оешма (клубы) булдырган. Хәрәкәтнең төбәк бүлеге җитәкчесе Тимур Сөләйманов әйтүенчә, һәр көн саен яңалары өстәлеп тора. Ике атна элек аларның саны 729 булса, хәзер инде – 1 меңгә якын.
Республикада хәрәкәткә 40 меңгә якын бала һәм яшьләр кушылган. Һәрбер районда 100–150гә якын бала, «алдынгылыкка» багышлау узып, хәрәкәт значогына ия булган. Сүз уңаеннан, Казанда 14тән 36 яшькә кадәр барлыгы 360 мең кеше исәпләнә.

Татарстанда 2023–2025 елларда күпфатирлы йортларны төзекләндерүгә 20 миллиард 114,7 миллион сум (моңа кадәр 18 миллиард 853,3 миллион сум каралган булган) бирелячәк. Премьер-министр Алексей Песошин имзалаган карардан күренгәнчә, капиталь төзекләндерүгә кузда тотылган акча күләме 6,6 процентка арткан. Барлыгы 2297 йорт: быел – 740, 2024 елда – 672, 2025 елда 885 йортны төзекләндерү каралган.

Ноябрь башында Татарстанда аномаль җылы һава көтелә. Айның беренче көннәрендә көндез һава температурасы +6...+11 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнге сәгатьләрдә дә җылы: +5...+8 градус. Синоптиклар фаразы буенча, өч көн шулай бик җылы торачак. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, ялларда болытлы һава, карлы яңгыр, көчле җил, бозлавык, кайбер районнарда – буран. Шимбә – 28 октябрьдә термометрның терекөмеш баганасы көндез +2...–1, төнге сәгатьләрдә 0...+5 градус күрсәтәчәк. Якшәмбе – 29 октябрьдә көндез +5 градуска кадәр, көньяк районнарда +8 градуска кадәр җылыта. Төнлә – 0 градус чамасы. Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, дүшәмбе – 30 октябрьдә юеш кар, көчле җил булыр дип көтелә. Һава температурасы тәүлек әйләнәсе +2...–2 градус чикләрендә тирбәләчәк.

Районнарда ни хәлләр?

Баулы

Олы яшьтә булуларына карамастан, спорт белән шөгыльләнүче пенсионерлар, ГТО нормаларын үтәп, яшьләргә үрнәк күрсәтә. Фатыйма Насыйрова 90 нчы яше белән бара. Һәр көнегүне тырышлык белән җиренә җиткереп ясый ул. Гәүдәсенең сыгылмалы һәм чыныккан булуы – күпьеллык тырышлык нәтиҗәсе. Асия Вәлиевага 87 яшь. «ГТО нормаларын тапшырганда минем өчен отжимание генә кыен булды. Яшь түгел бит инде. Бабай белән икебезгә дә 87 яшь хәзер. Бик яратып гимнастикага йөрибез, аннан теннис белән шөгыльләнәбез, бассейнга йөрибез, төштән соң скандинав йөрешенә чыгабыз», – ди ул. Миннесәрия Йосыповага 85 яшь. «Пенсиягә чыкканнан бирле актив тормыш алып барырга тырышам. Көненә өч километр җәяү йөрим, хәзер спорт залына йөрим. Монда аралашабыз, бик күңелле. Әле бирешмибез», – ди ул. («Баулы-информ»)

Азнакай

Районда Октябрь-Бүләк авылының 100 еллыгын билгеләп уздылар. Авылдашлар, якташлар туган авылларының юбилеена багышланган тантаналы чарага җыелды, шунда ук Октябрь-Бүләк тарихына багышланган китап тәкъдим ителде. Бәйрәм чарасы юбилей истәлеге итеп ясалган нигез ташы янында башланып китте. Соңыннан гомер юлын туган авылына багышлап, аның үсешенә зур өлеш салган, озак еллар «Киров» колхозында бригадир вазыйфасын башкарган Әнәс ага Гадиев истәлегенә ул яшәгән йортта мемориаль такта ачылды. Бәйрәмнең төп өлеше авыл мәдәният йортында үтте. Район башлыгы Марсель Шәйдуллин барлык авыл халкын, кунакларны әлеге истәлекле чара белән котлап, җирлек башлыгы Артур Ногмановка 100 мең сумлык сертификат тапшырды. («Азнакай»)

Саба

Юлбат авылы кызы Альбина Галиева «Миссис International – Россия 2023» бәйгесендә җиңү яулаган. Ул, Татарстан данын яклап, «Миссис Universal – Россия 2023» исеменә лаек булган. Ростовта узган бәйгедә илнең төрле төбәкләреннән килгән 13 хатын-кыз көч сынашкан. Анда катнашучылар, милли киемнәр киеп, үзләре белән таныштырган. Шулай ук һәр төбәккә хас милли ризык тәкъдим иткәннәр. Бу этапта Альбина бәрән ите һәм кыздырма пешереп күрсәткән. Ә бәйгенең хөкемдарларына Сабада ясалган чәкчәк, татар чәе һәм бал алып барган. Альбина Юлбат авылында туып-үскән. Сабада һәм Татарстанның башка районнарында бию студияләре ачкан. Авыру балалар белән дә эшли. Аның Даун синдромлы балаларга юнәлтелгән проектлары бар. («Татар-информ»)

КҮРШЕЛӘР – ЯХШЫ КЕШЕЛӘР

Татарстан Рәисе Иран Ислам Республикасының икътисад министры урынбасары Мөхәммәд Джавад Шәрифзадә белән очрашты. Бу ил делегациясе Татарстанга Казанда «Банк Мелли Иран»ның бүлеге «Мир Бизнес Банк»ның офисын ачу тантанасында катнашу өчен килде. Рөстәм Миңнеханов очрашуда әлеге проектны Татарстан белән Иран арасындагы хезмәттәшлекне тормышка ашыруның ачык мисалы дип атады.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан Россия – Иран мөнәсәбәтләре кысасында бу ил белән хезмәттәшлеккә зур игътибар бирә. Татарстан Рәисе ике илнең яхшы күршеләр булуын һәм кискен халыкара мәсьәләләрне бергәләп хәл итүен әйтте. Аның фикеренчә, бүгенге шартларда безнең дәүләтләрнең хезмәттәшлеге аерым әһәмияткә ия. Газзә секторында килеп чыккан кризисны хәл итү өчен халыкара җәмәгатьчелекнең тырышлыгы кирәк.

– Безнең лидерлар һәрвакыт элемтәдә. Иранның Шанхай хезмәттәшлек оешмасында тулы хокуклы катнашучы булуы да сөендерә, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов Иран Президенты Эбрахим Раиси белән шәхсән таныш булуы, аның 2018 елда Татарстанга килүен искә алды.

– Без Иран Президентына республикага һәм хезмәттәшлек мәсьәләләренә игътибарлы булганы өчен рәхмәтле, – диде ул. – Мин Иранга һәрвакыт бик теләп барам. Тәһран һәм башка провинцияләр белән элемтәләребез яхшы. Соңгы тапкыр Иранга узган елның сентябрендә бардык, Тәһранда, Гөлестан һәм Көнчыгыш Азәрбайҗан провинцияләрендә булдык. Быел Көнчыгыш Азәрбайҗан провинциясе губернаторы безнең республикага килде.

Татарстан һәм Иран арасында сәүдә хезмәттәшлеге турында меморандум төзелгән. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, ике арадагы хезмәттәшлекне үстерүгә Иранның Казандагы генераль консуллыгы да зур өлеш кертә.

Мөхәммәд Джавад Шәрифзадә Татарстан белән хезмәттәшлекнең Россия белән Иран арасындагы мөнәсәбәтләрне үстерүгә зур өлеш кертүен әйтте һәм Рөстәм Миңнехановны бу илгә янә сәфәр белән килергә чакырды.

ХЕЗМӘТ ӘҖЕРЕ

Җитештерү, сәламәтлек саклау, мәдәният, фән һәм техника... Казан Кремлендә республиканың әнә шул тармакларында хезмәт куйган алдынгыларга дәүләт бүләкләре тапшырдылар. Дәрәҗәле бүләкне алар Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин кулыннан алды.

Парламент башлыгы үз чыгышында бу тантананың матур традициягә әверелүен билгеләп үтте.

– Бирегә төрле тармакта эшләүче һөнәр ияләре – җитештерү башлыклары, инженерлар, фән эшлеклеләре, табиблар, артистлар, хезмәт ветераннары җыелган. Алар барысы да республиканың социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш кертә. Сез – безнең горурлыгыбыз, күпләргә үрнәк булып торасыз. Сезнең фидакарь хезмәтегез ярдәмендә республика бүгенге сынауларга бирешми, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Парламент башлыгы авыл хуҗалыгында эшләүчеләргә рәхмәт әйтте. Моннан тыш ул нефть-газ һәм нефть химиясе, сәнәгать һәм төзелеш тармагы үсешен дә югары бәяләде. Фәрит Мөхәммәтшин Татарстанның цифрлы технологияләр үсеше ягыннан да алдынгы төбәкләрнең берсе булуын билгеләп үтте.

Дәүләт бүләкләре барлыгы 51 кешегә тапшырылды. Бүләкләнүчеләр арасында иң өлкәне – Казан федераль университетының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Марсель Бакиров. Аңа тагын бер айдан туксан яшь тула икән. Студентларның остазы Марсель ага «Дуслык» ордены белән бүләкләнде.

– Мин бик өлкән кеше инде. Гомернең соңгы чорында үткәннәрне барлыйсың икән ул. Ничек яшәдем? Тормыш заяга узмаганмы? Узганнарга борылып карыйм да, шөкер, дим. Яраткан эшемдә – университетта 53 ел хезмәт куйдым. Башта – аспирантурада, аннан студентларга белем бирдем. Укытучы фән белән шөгыльләнергә тиеш бит әле. Фольклор дәреслеге, шигырь төзелеше, татар, төрки халыкларга бәйле хезмәтләр яздым. Яратып кабул иткәннәр дип ышанам. Ни өчен дигәндә, бер генә тапкыр да тәнкыйть сүзе ишетмәдем. Әгәр тыйнак хезмәтемне орден белән бәяләгәннәр икән, тормышым бушка үтмәгән, димәк. Шушы олы бүләккә тәкъдим итүчеләргә дә, карарга кул куйган Рәисебезгә дә рәхмәт, – диде Марсель Бакиров.

Тантана күптән күрешмәгән дусларны да очраштырды. «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеменә лаек булган композитор, продюсер Марат Әхмәтшин Казан Кремлендә армиядә бергә хезмәт иткән дустын очраткан. 35 елдан соң! Бу бит үзе бер әкият кебек. Валерий Иванов исә II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләнде. Ул – «ПОЛИМЕТАЛЛИНВЕСТ-НК» оешмасы директоры.

– Валера белән 35 ел күрешкән булмады. Украинада бергә хезмәт иткән идек. Ул армия сафларына – Түбән Камадан, ә мин Бөгелмәдән киттем. Хәрби хезмәттән дә бер поездда утырып кайттык. Шуңа күрә безнең өчен бүгенге очрашу шаккатарлык булды. Әле дә бу вакыйгага ышанып җитә алмыйбыз, – ди Марат Әхмәтшин.

Парламент Рәисе кулыннан дәүләт бүләкләре алучылар арасында хезмәттәшебез, газетабызның мәгариф һәм фән бүлеге мөдире Сәрия Мифтахова да бар иде. «Татарстанның атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре» дигән дәрәҗәле исемгә лаек булды ул. Хезмәттәшебезне чын күңелдән котлыйбыз! Иҗат чишмәң беркайчан саекмасын, каләмең тутыкмасын!

Республика тире һәм йогышлы авырулар диспансерында шәфкать туташы булып эшләүче Светлана Мифтахованың күкрәгендә «Фидакарь хезмәте өчен» медале балкый хәзер. Сөенечтән, күзләреннән яшьләр тәгәрәде аның. Бер урында – 47 ел! Хезмәт кенәгәсендә – бары бер тамга. Светлана ханым, авыруларга дәва бирә алуым белән бәхетле, ди.

«Чаян» журналының бүлек редакторы, танылган юмор остасы Алмаз Хәмзин да – нәкъ шундый ук дәүләт бүләге иясе. Мондый дәрәҗәле исемнәр белән бүләкләнүчеләрне бик күп еллар карап утырган ул. Көнләшеп түгел, башкаларның уңышларына сөенеп. Үзе исә кайчан да булса шушы залда олы бүләк алырмын дип башына да китермәгән.

– Ниһаять, мине дә чакырдылар. Эшләмәгән кеше түгел бит. Нинди генә өлкәдә нинди генә хезмәтләр башкармадым. Барысын да җиренә җиткереп эшләдем. Шуңа күрә лаеклы бүләк дип саныйм, – диде Алмаз Хәмзин.

«Татар-информ»

305 МЕҢ СУМ ТҮЛИЛӘР

Татарстанда контракт нигезендә хезмәт итүчеләргә 305 мең сум күләмендә акча түләнәчәк. Бер мәртәбә түләнә торган бу акчаны ике категориягә караган кешеләр ала. Контрактның 2023 елның 31 августыннан соң төзелгән булуы шарт. Бу хактагы Указны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов имзалады.

Беренче категориягә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә Татарстан Республикасы территориясеннән мобилизация буенча чакырылган кешеләр керә. Икенчесенә хәрби хезмәткә чакыру буенча алынып, контрактны Татарстандагы хәрби комиссариатларда яисә республикада урнашкан хәрби частьларда төзегән кешеләр карый.

Указ быел 31 декабрьгә кадәр гамәлдә.

БАТЫРЛЫК КҮРЕНСЕН

Горурлык һәм рәхмәт билгесе. Башкалада ачылган яңа күргәзмәне әнә шулай дип бәяләделәр.

Казанда махсус хәрби операциядә катнашучылар хөрмәтенә «Россия Геройлары. Республика Геройлары» дип аталган фотокүргәзмә эшли башлады. Ул «Казан ярминкәсе» күргәзмә үзәгендә «Бердәм Россия» партиясе һәм «Бердәм Россиянең яшь гвардиясе» иҗтимагый оешмасы тәкъдиме белән оештырылган. Ачылыш чарасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин һәм хәрбиләрнең туганнары да катнашты.

Күргәзмә махсус хәрби операция барышында күрсәткән батырлыклары өчен Россия Герое исеменә лаек булган хәрбиләргә багышланган. Алар арасында Ватан алдындагы бурычын үтәгәндә һәлак булучылар да, бүген сафта булган хәрбиләр дә бар. Биредәге фотосурәтләрдә илнең яңа төбәкләрендә волонтерлар эшен дә күрергә мөмкин.

– Әлеге күргәзмә аша без Геройларыбызга олы хөрмәтебез һәм рәхмәтебезне белдерәбез. Илне яклап батырларча һәлак булучыларның истәлеген күңелләрдә сакларга телибез. Геройларыбыз халык хәтерендә чын патриотлар булып калачак, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы Рәисе билгеләп үткәнчә, бу кешеләрнең исемнәре Татарстан гына түгел, ә Россия тарихы елъязмасында алтын хәрефләр белән язылган.

– Без якташларыбыз белән горурланабыз һәм үз иленең чын ватанпәрвәрләрен тәрбияләгән әти-әниләренә рәхмәт белдерәбез. Геройларыбызның гаиләләренә ярдәм итүне алга таба да дәвам иттерәчәкбез, – диде ул.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, Татарстанда яшәүчеләр махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм илнең яңа төбәкләрендә яшәүчеләргә зур ярдәм күрсәтә. Бүген аларга бер мең тоннадан артык гуманитар ярдәм озатылган инде.

tatarstan.ru

– Әлеге күргәзмә аша бик күпләр, бигрәк тә яшьләр, Геройларыбызның батырлыгы турында беләчәк дип ышанабыз, – дип тә искәртте «Бердәм Россия» партиясенең төбәк штабы җитәкчесе Руслан Шиһабетдинов.

Күргәзмәдә яу кырында батырларча һәлак булган Дамир Исламов һәм Дамир Гыйлемханов фотоларын да күрергә мөмкин. Исегезгә төшерәбез: узган елның мартында танк командиры – өлкән лейтенант Дамир Исламов, механик-йөртүче Дамир Гыйлемханов экипажы дошманның дүрт танкын тар-мар итте. Россия Президенты Указы нигезендә аларга Россия Герое исеме бирелде. Күргәзмә геройлары арасында Ватан алдындагы бурычын үтәгәндә «Алтын йолдыз» медале белән бүләкләнгән биш якташыбыз: Раил Габдрахманов, Иван Додосов, Александр Лапин, Ирек Мәгъсумов һәм Рәсим Баксиков та бар.

Элемтәдә

Тамчыдан ярдәм җыела. Илдә өлешчә мобилизация башланганнан бирле республикада хәрбиләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм чаралары дәвам итә. Бу хакта Татарстанда Волонтерлыкны үстерү буенча ведомствоара совет утырышында да сөйләштеләр.

Министрлар Кабинетында Татарстан вице-премьеры Ләйлә Фазлыева җитәкчелегендә узган чарада «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» республика хәрәкәте эшчәнлеге турында сөйләштеләр. Алар бүген республикада якыннары мобилизацияләнгән 10 меңнән артык гаилә белән даими эш алып барыла. Аларга федераль, республика һәм муниципаль дәрәҗәдәге ярдәм чаралары турында мәгълүматны да вакытында хәбәр итеп торалар.

– 13 октябрьгә алынган саннарга караганда, Татарстанда гамәлдә булган «кайнар линия» телефоннарына хәрбиләргә һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтүгә бәйле 65 меңнән артык мөрәҗәгать килеп ирешкән. Аларны тиз арада хәл итү өчен тиешле чаралар күрелде, – дип сөйләде утырышта әлеге эш белән шөгыльләнүче «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» республика хәрәкәте координаторы Ринат Фазылов. – Без һәр шалтыратучы белән җентекләп сөйләшәбез. Хәрбиләрнең гаиләләреннән килгән мөрәҗәгатьләрне тикшерәбез. Чөнки халыкның хакимият органнарына ышанычы безнең эшнең нәтиҗәлелегенә бәйле.

Ринат Фазылов билгеләп үткәнчә, хәрәкәт вәкилләре башкарган эшләр турында ярдәм.рф сайтыннан да белергә мөмкин. Биредә, шул исәптән социаль челтәрләрдә дә бөтен мәгълүмат ике дәүләт телендә тәкъдим ителгән. Сайтта махсус хәрби операция зонасындагы хәрбиләргә кирәкле товарлар буенча бүлек командирларыннан килгән гаризалар да бар. Шуңа күрә теләге булган һәркем солдатларга ярдәм күрсәтүдә катнаша ала.

Быелның 13 октябренә алынган мәгълүматларга караганда, республика складларында хәрбиләргә дип 220 меңнән артык бирәмлек әйбер җыелганнар. 2022 елның октябреннән 2023 елның сентябренә кадәр вакыт аралыгында якташларыбыз хезмәт иткән 12 хәрби подразделениегә ярдәм күрсәткәннәр. Махсус хәрби операция зонасына бар җирдән үтә алучы биш машина озатканнар. Якын арада тагын шундый ике автомобиль җибәрергә ниятлиләр. Әле күптән түгел генә, 7 октябрьдә Татарстан егетләре хезмәт иткән 1231 нче полкка 2,5 мең тонналы ярдәм киткән. «Ноябрь ахырында чираттагысын җибәрәчәкбез», – диде Ринат Фазылов. Моннан тыш, Татарстан шефлыкка алган Рубежное һәм Лисичанск шәһәрләре хастаханәләренә һәм гади халыкка да даими ярдәм күрсәтәләр.

«Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» республика хәрәкәте хәрбиләргә булышучы волонтерлык берләшмәләренә ярдәм күрсәтү һәм координацияләү буенча эшне дә дәвам иттерә. Аерым алганда, ул волонтерлык берләшмәсе белән тыгыз хезмәттәшлек урнаштырганнар. Хәрбиләргә ярдәм күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне бергәләп хәл итү өчен аларны киләчәктә республика хәрәкәтенә берләштерү дә күздә тотыла.

«Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» эшчәнлеге – саннарда

10596 гаилә белән элемтә корылган

65442 мөрәҗәгать кабул ителгән

220813 бирәмлек әйбер җыелган

Әйтеп кенә бактым

Самогон

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Казан урамы буйлап барганда, бер кибет өстендәге язуга күз төште. Зур итеп «Самогонные аппараты» дип язып куйганнар. Кеше күзенә ташлансын диптер инде, шундый матур хәрефләр белән язганнар, күз ташлану гына түгел, борынга самогон исе килеп бәрелгәндәй булды.

Ярый, исе чурт с ним, миңа Казанда шундый кибет булуы сәер тоелды. Тоелмас иде, безнең гомернең шактый өлеше самогон куучыларга каршы аяусыз көрәш барган елларга туры килде бит. Бу көрәш җәмгыять тормышында шундый зур, әһәмиятле урын алып тора иде ки, хәтта 1961 елда «Мосфильм» киностудиясендә «Самогонщики» дигән кыска метражлы нәфис фильм чыкты. Көлкеле маҗарага корылган бу фильмны караганда, миллионлаган кеше эче катып көлгәндер. Шул ук вакытта самогон куучы өч жулик – Трус, Балбес, Бывалыйга карата нәфрәт, ә аларны кулга алган һәм машинага утыртып алып киткән милиционерларга рәхмәт хисләре дә уянмый калмагандыр. Кино тәмамланганда, авыл клубында юкка гына: «Шул кирәк сезгә!», «Милиция маладис!» дип кычкырмаганнардыр.

Ә бүген? Кичә генә кара булган нәрсәләр бүген ак. Җәмгыять 180 градуска борылды.

Үзем хәмер белән күптән чуалмыйм. Әмма шактый күп кешенең, хәтта кайбер җитәкчеләрнең дә аракы урынына самогонны өстен күрүләре турында ишеткән бар. Янәсе, ул чистарак та, файдалырак та икән. Шулайдыр, юкса самогонны элек-электән матур итеп «көмешкә» дип йөртмәсләр иде. Без дә яраткан хатыннарыбызга «алтыным-көмешем» дибез бит.

Ярый, көмешкәне аракыга караганда затлырак дип табалар икән, эсселәр дә, аның гаебе юк. Тик менә соңгы елларда аракының абруе төшкән саен, казнага спиртлы эчемлекләр сатудан кергән акча күләме дә кимегән, ди. Татарстанда гына түгел, бөтен илендә шул ук хәл икән.

Инде нишләргә? Самогон куучыларга каршы аяусыз көрәш башлауның мәгънәсе юк. Тыюлар белән тормыштагы тискәре күренешләрне бетереп булмаячагына күптән төшендек. Хәмер сату вакытларын да үзгәртеп карадык, айныткычлар да эшләп торды, хәтта «коры законнар» да керттек, тик эчүчелекнең, самогон куунның тамырына балта чабып булмады. Әле бит акча-макча мәсьәләсен дә хәл итәсе бар. Әйтүләренчә, хәмер сатудан кергән акциз салымнары бюджет кеременең шактый өлешен тәшкил итә икән. Димәк, аракы аз сатылса, казнага акча да аз керә дигән сүз. Хәмер дигәннәре тәки баш авыртуына әйләнде. Инде менә киләсе елдан алкогольле эчемлекләргә бәя күтәрмәкчеләр. Ә Федерация Советы спикеры Валентина Матвиенко, гомумән, Россиядә җитештерелүче этил спиртына, шул исәптән медицинада һәм парфюмериядә кулланыла торганына да салым салырга кирәк, дигән фикердә.

Шул ук вакытта «ялган аракы»га каршы көрәшне тагын да аяусызландыру турында да уйланалар. Ә самогон дигәннәрен нишләтерләр инде. Кайбер илләрдәге кебек, көмешкәне дә казнага акча кертә торган итәрләр. Артык ирекка чыгармаслар, аракы заводларына көндәш була алу дәрәҗәсенә җиткермәсләр үзе, әмма акча эшләү көсебенә дә әйләндермәсләр.

Әйе, бу самогон дигәннәре башны бутый башлады. Кирәкмәс сүзләр әйтеп ташлаган булсам, гафу итегез, яме! Нидер әйтеп бетермәгән булсам, үзегез өстәп сөйләгез.

ӘДӘБИЯТ ҺӘМ ТӘРБИЯ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Мәктәптән киткәнгә күп еллар узса да, әледәнәле «Учительская газета»ны укыйм. Укыйм дигәч тә, барлык язмаларны да түгел. Мине, беренчедән, язманың авторы булган шәхес, икенчедән, ул күтәргән проблема җәлеп итә. Шул ике критерий туры килсә, язма минеке. Соңгы санда Айзерманның «Знания и понимание» дигән язмасы урын алган. Айзерман – атаклы шәхес, аның язганы фикерле була.

Болай үзе бик әллә нәрсә яңалык ачмаган, әдәбият имтиханында укучылардан стандарт һәм әзер фикерләр әйтергә мәҗбүр итүләрен тәнкыйтьләгән. Бүгенге чыгарылыш имтиханнары системасына да эләккән. Болар – барыбызга да таныш проблемалар. Һәм күпме генә язма, барыбер хәл ителмәячәк мәсьәләләр. Газета сайтындагы бер язма исемен генә китерик: «Преподавать некогда: в Челябинской области предлагают снизить бумажную нагрузку на учителей». Эшкә килгәндә, шул проблеманы хәл итү вәгъдәсе белән килмәгән бер генә министрны да белмим мин. Министрлар килә дә китә, проблема кала. Кала гына түгел, зурая да әле. Аның хәл ителмәвенең сәбәбе бер генә: безнең мәгариф бюрократиясе әзер колейдан чыгудан курка, чөнки… шулай тәрбияләнгән.

Әдәбияттан имтихан сочинениесе ничек языла? Күчерелә. Укытучы күрмәмешкә салыша, хәтта күчерергә мәҗбүр дә итә. Вузга кабул итү имтиханында да сочинение язуның ике генә юлы бар: я шпаргалкадан күчерәсең, я хәтере яхшы булганнар хәтердә калган стандарт фикерләрне кәгазьгә төшерә. Мин үзем, укырга кергәндә, «Образы положительных героев в романе Толстого «Война и мир» дигән темага иншаны күчерми «бишле»гә яздым, әмма романның өч битен дә укымаган, дәреслектәге анализны гына үзләштергән идем. Система шундый һәм билгеләнгән чикләрдән чыга башласаң, имтиханны тапшыра алмыйсың.

Айзерман да шул турыда яза. Инша язарга алты сәгать вакыт бирелә. Ул вакыт эчендә каяндыр күчермичә, оригиналь алты битлек эш язып тапшыру физик яктан мөмкин дә түгел. Аны бит башта каралама да язасы, аннан хатасыз итеп чистага күчерәсе. Арып-алҗып беткән килеш хатасыз язу мөмкин ук эш түгел. Шулай булгач, безнең әдәбият дәресләре һәм имтиханнары калыпка салынган кешеләр тәрбияли, болар уйлап тормый, ә әзер фикерләрне кабул итәргә гадәтләнә. Кайчандыр бер бунтарь егет Островскийның «Гроза» әсәренә «Луч света в темном царстве» дигән тәнкыйть мәкаләсе яза да иренә хыянәт иткән һәм соңыннан үзенә кул салган хатын образын байрак итеп күтәреп калдыра. Безнең әдәбият дәреслекләре һәм имтиханнары ул байракны югары тоту өчен барысын да эшли.

Бездә әдәбият уку яхшы тәрбия бирә дигән фикер яши. Өлешчә дөрес, әмма нигездә ялгыш фикер бу. Нәрсә укыйсың һәм аңа нинди караш булдырасың бит әле. Яшьлектә мин Есенин иҗаты белән мавыктым. Аның байтак шигырен яттан белә идем. Колоритлы тел, тиңсез образлар, метафоралар… Шагыйрь иҗатын яратмыйча мөмкин түгел. Әмма автор тәртипсез тормыш алып барган, эчкече булган һәм мантыйкый рәвештә тормышын фаҗигале төгәлләгән. Болар барысы да аның иҗатында чагыла һәм укучыга да үтеп керә. Есенин тормышка карашыма һәм фикерләү рәвешенә кирәгеннән артык үтеп керде. Аның романтикасы шәхесемә тискәре тәэсир ясавын соң аңладым. Әйе, без яшәгән җәмгыятьтә бераз хулиган булмасаң, яшәү кыен да булыр иде. Хулиганлык кайбер вакытларда стимул да бирде. Стимул дип латин телендә хайван куа торган очлы таякка әйтәләр. Есенин тудырган калыпка керү кайчакларда миңа шул таяк ролен үтәде. Вузда уку артык җиңел бирелә иде. Бу ваемсызлыкка этәрә. Лекцияләрнең конспектлары



Илдар Мөхәммәтҗанов

язылмый, гамәли дәресләргә әзерләнеп киленми, дәресләр күп калдырыла. Укытучы андый тәртипсезлеккә игътибар итә һәм имтихан белән яный. Шунда студент оятсыз рәвештә аларның йөзенә туры карап: «Мин Сезнең имтиханны «бишле»гә бирәчәкмен», – ди. Шунда ук имитиханның ике төрле ставкасы куела: профессор-доцентлар иң түбән бәяне юрый, син – максималь югарыны. Ставка куелгач, аңа омтыласың. Имтихан алдыннан җан-фәрманга тырышасың: конспектны яхшы язып барган берәр кыз белән дуслашасың, беренче чыганакларны өйрәнү өчен, китапханәгә чабасың, баш та күтәрми укый башлыйсың. Укытучылар белән төзелгән «пари»ның берсен генә оттырдым: политэкономия имтиханы «дүртле»гә тапшырылды.

Ике меңенче еллар башында гына өлкән класста укучы бер кызның: «Есенин – бөек талант, әмма үз тормышын үзе кора белмәгән шәхес укучыга файдалы ни бирә ала?» – дигән фикере белән таныштым. Шул фикерне үсмер чакта әдәбият дәресендә әйтсәләр, бәлки, мин башкачарак формалашыр идем. Еллар үтеп, чәчләр-сакаллар агаргач, без, вузда укыган сабакташлар, «Ватсап» төркеме оештырдык, һәм конспектларын уртак файдаланып, имтиханнарга бергә әзерләнгән кыз, хәзер инде абруйлы ханым: «Син яшьлектәге теге холкыңны һаман да ташламагансыңдыр дип уйлыйм», – дип искә алды. «Есенин»ны үземнән этеп чыгару өчен күп тырыштым мин. Әмма «эз»е калды. Институтта укыганда, Фәрит Хатиповтан дәресләр алу китапларга башка күз белән карарга өйрәтте. Остаз әдәби образ артындагы бөтенләй башка фикерләрне күрә белә иде. Көчле совет цензурасы елларында да, калыптан чыгып, «кыйналган» әсәрләргә дә югары бәя бирүдән курыкмады. Аның җитәкчелегендә берничә курс эше һәм диплом эше эшләү күп нәрсәгә өйрәтте. Язылганнарга тәнкыйди күз белән карый белә башладым. Диалектик материализмны өйрәнгәндә, таләп ителмәсә дә, Ленинның «Материализм һәм эмпириокритицизм» дигән калын китабын укып чыктым. Хәтерлим: тетрәндерде һәм депрессиягә салды ул китап мине. Үткән ел Казаннан, нindидер документаль фильм эшлибез дип, рус телле берничә егет килеп төште. Үтенеп-ялынып, миннән камерага интервью алдылар. Шунда аларга әйттем: «Исламга килүемдә мөһим этәргечне Ленин бирде», – дидем. Алар гаҗәпләнделәр, билгеле, яшь булсалар да, Ленинны ишетеп беләләр икән. Китап, әдәби әсәр генә түгел, гомумән, китап, безнең тормышыбызны формалаштыруда хәлиткеч роль уйный. Шуңа күрә әдәбият дәресләренә салкын карарга ярамый. Айзерманны укыганда, шуларны уйладым.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

УЙНАП ТҮГЕЛ, УЙЛАП БАС

Казанда яшәүче Гөлназ Габделвәлиевага көннәрдән бер көнне бер-бер артлы таныш-белешләре шалтырата башлый. Телефонны алышка барысы да: «Нәрсә булды? Ул акча сиңа нәрсәгә кирәк?» – дип сорыйлар. Баксаң, «Ватсап»та аларның һәркайсына Гөлназ исеменнән: «Бер үтенечем бар: иртәгә кадәр картама 70 мең сум сум акча күчереп тора алмыйсыңмы? Төшкә кадәр кайтарам», – дигән смс-хәбәр килгән икән.

Исәнме юк, саумы юк. Гөлназның кеше белән гомердә дә болай аралашмавын яхшы белгән якыннары аптырашта кала. Акча күчерер алдыннан иң элек үзенә шалтыратып, хәлен белешергә була алар. Мошенникларның яңа алдау ысулын үз җилкәсендә татыган Гөлназның төп башына утыру тарихы әнә шулай башлана.

– Башта эшнең нидә икәнен аңлый алмый интектем. Шалтыраткан берсенә: «Миңа акча кирәкми, бар да тәртиптә, мин андый смс җибәрмәдем», – дидем. «Ватсап»та язышу тарихына кереп карасам, дөрестән дә, телефон кенәгәсендә язылган кешеләргә минем исемнән шундый смс-хәбәр киткән. Әмма мин аны җибәрмәдем. Димәк, минем исемнән мошенниклар җибәргән булып чыга, – ди Гөлназ.

Бәхеткә, аның исеменнән ялган смс-хәбәр алган танышларының берсе дә мошенникларга акча күчерергә өлгермәгән. Аларның берсе бу смс-хәбәргә җавап та язган. Тегеләре исә, ялганнары тотылганны аңлап, ул кызга сүгенү сүзләре белән җавап кайтарган.

– «Ватсап»ны белгечләргә дә күрсәттем. Тикшерә торгач, бу хәлнең ни сәбәпле килеп чыкканын аңыштык. Моннан берничә көн элек телефонга танышымнан «бәйгедә катнашкан сеңлем өчен шушы сылтама буенча кереп тавыш бирче» дигән смс-хәбәр алдым. Эш буенча мондый тавыш бирүләрдә бик күп катнашырга туры килә. Шуңа күрә бу юлы да, аны-моны уйламыйча, сылтама буенча кердем дә тавыш бирдем. Баксаң, бу хәбәр мошенниклардан килгән булган һәм алар мин тавыш биргәннән соң минем «Ватсап»ны «җимерергә» дә өлгергән. Аннары әнә шул смс-хәбәрләрне таратканнар, – ди Гөлназ.

Атта да, тәртәдә дә

Гөлназ кебек кыен хәлдә калучылар турында соңгы арада әледән-әле ишетергә туры килә. Күптән түгел шундый ук хәл Чаллыда кабатланган. Билгеле оешмаларның берсендә хисапчы булып эшләүче 52 яшьлек ханым ярдәм сорап язган танышына 44 мең сум акча күчергән. Казандагы вузларның берсендә укыткан мөгаллим исә шул рәвешле 45 мең сум акчасыннан колак каккан.

Зыян күрүчеләр мошенникларны гаепләсә, белгечләр бу очракта гаеп атта да, тәртәдә дә дип саный. Башкаладагы шәхси оешмаларның берсендә эшләүче киберкуркынычсызлык буенча белгеч Руслан Гарипов сүзләренә караганда, бүген иң беренче чиратта кеше үзе аң булырга тиеш.

– Мошенник корбаны булган кешеләрнең кайсы белән генә сөйләшмә, «мин берни дә эшләмәдем, беркая кермәдем, басмадым, тик торганда шулай килеп чыкты» ди. Алай була алмый. Телефоныңны җимергәннәр икән, димәк, син нindидер сылтама буенча кергәнсең. Күп очракта телефонга вирус әнә шундый чакта эләгә. Шуңа күрә кайсыдыр сылтама буенча кереп, нәрсәдер эшләргә кушкан смс-хәбәр алгансыз икән, иң элек анда язылган сүзләргә игътибар итәргә кирәк. Сылтамада күрсәтелгән ресурс таныш түгел икән, анда керергә ярамый. Шул ук «Ватсап» кушымтасы да кулланучыларына куркынычсызлык кагыйдәләре турында даими рәвештә искә төшереп тора. Игътибар белән укырга гына кирәк, – ди белгеч.

Сүз уңаеннан, «Ватсап» вирусларга иң тиз бирешүчән кушымта икән. «Касперский лабораториясе» белгечләре махсус тикшеренү уздырганнан соң шундый нәтиҗәгә килгән. «Телеграм» да калышмый. «Касперский лабораториясе» белгече Егор Бубнов көндәлек тормышта кулланылган мессенджерларга килгән һәр мәгълүматка сак карарга киңәш итә.

– Ялган сайтка кертүче сылтама аша күчкәч, мошенниклар кешенең телефонына тулысынча хуҗа була ала. Бу очракта инде алар кеше исеменнән ялган хәбәрләр генә җибәреп калмыйча, аларның кемнәр белән нәрсә турында язышуын күрә, шул рәвешле корбаны турында тулы мәгълүмат туплый, онлайн банктагы акчасын урлый, хәтта телефондагы шәхси мәгълүмат ярдәмендә кешене шантажлый ук ала. Шуңа күрә «Ватсап», «Телеграм» кебек мессенджерларны ике катлы пароль (аутентификация) ярдәмендә саклана торган итеп үзгәртергә кирәк, – ди белгеч.

Халыкны төп башына утыртуның яңадан-яңа алымнарын уйлап табып торучы мошенниклар соңгы арада татар эстрадасы артистлары исеменнән дә эш итә башлады. Күптән түгел генә Татарстанның атказанган артисты Данир Сабировның күршеләрендә коточкыч янгын чыкты. Шул хакта видеолар таралгач, артистның күпсанлы язылучылары арасында мошенниклар активлашып китте. Алар видео астындагы комментарийларда халыктан акча сорап яза, реквизитларын калдыра башлады. Җырчы исеменнән шәхсән акча сорап язылган смс-хәбәр алучылар да булган.

Данир Сабиров шуннан соң үз сәхифәсендә аның исеменнән мошенниклар эш итүен хәбәр итте. Аңа кадәр Татарстанның атказанган артисты Илсөя Бәдретдинованың Чаллыда узачак концертларына «ярты бәядән» дип алдап билет сатучы кырыгалдарлар пәйда булган иде. Җырчы язылучыларын, әлеге ялган билетлар белән концертларга кереп булмаячак, дип кисәтте. Әмма җырчылар үзләре бу хакта ачылып сөйләшергә теләми. Һәрхәлдә, «ВТ» хәбәрчесе бу уңайдан бирелгән сорауларына җавап таба алмады.

Уен аша да аулый

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, республика халкы дистанцион рәвештә эш итүче кырыгалдарларга атна саен 20 миллион сум акча күчерә.

Соңгы арада мошенниклар үзләренең кырын эшләренә үсмерләрне дә күпләп җәлеп итә башлаган. Аларга, нигездә, курьер буларак эшләргә тәкъдим итәләр икән. Әле бу көннәрдә генә хокук сакчылары Әлмәттә шундый кырын юлга баскан 15 яшьлек мәктәп укучысын тоткарлады. Мошенниклар сүзенә ышанып, «бәлагә тарыган» танышына ярдәм итәргә теләгән 86 яшьлек әбидән 100 мең сум акча алып, шуны кырыгалдарларга тапшырырга тиеш булган ул. Әмма өлгерми – хокук сакчылары тиз арада эзенә төшә.

Мошенниклар үсмерләрне социаль челтәрләр, мессенджерлар аша таба, дип кисәтә хокук сакчылары. Алар җиңел акча дигән игъланга алдана. Әмма үсмерләр мондый кырын эшкә ризалашыр алдыннан шунысын белсен иде: мошенникларның эзенә төшәр алдыннан, кагыйдә буларак, иң элек арадашчыларны, шул ук курьерларны тоткарлыйлар.

Юрист Илнур Галимуллин сүзләренә караганда, закон нигезендә хәзер арадашчылар да җинаять җаваплылыгына тартыла. Корбанга салган матди зыянны кире кайтару бурычы да еш кына арадашчылар җилкәсенә төшә. Яше тулмаган булса, бала өчен моны ата-анасына эшләргә туры киләчәк.

Соңгы арада мошенниклар балалар кулы белән баюның тагын бер ысулын куллана башлаган. Бу кармакка, нигездә, компьютер уеннары белән мавыккан балалар эләгә икән. Казанда шундый берничә очрак теркәлгән инде. Компьютер уены барышында мошенниклар балага герой өчен фәлән әйбер сатып алырга тәкъдим итәләр. Аптырап калган балага акчаны кайдан аласын да өйрәтәләр. Шуннан соң бала аңа ата-анасының карта номерын әйтә. Ул арада мошенниклар картадагы акчаны салдырып та куя.

Мондый аянычлы очраклардан саклану өчен, хокук сакчылары бала белән гел аралашып, аның кызыксыну, мавыгуларыннан хәбәрдар булырга куша. Ата-ана баласының телефонда нинди уеннар уйнавын, интернет аша нәрсәләр сатып алуын да тикшереп торырга тиеш. Балага шәхси мәгълүматны, карта номерларын чит кешегә әйтергә ярамаганлыгын да искәртеп торырга кирәк.

dreamstime.com

АЛДАНМАС ӨЧЕН НӘРСӘЛӘРНЕ ИСТӘ ТОТАРГА?

➤Телефондагы «Ватсап», «Телеграм» ише мессенджерларны, социаль челтәрләрдәге сәхифәгезне ике катлы пароль (аутентификация) ярдәмендә саклана торган итеп көйләгез.

➤Якын кешегезгә ярдәм кирәк, дип шалтыратсалар, аның үзе белән сөйләшмичә, берни дә эшләмәгез.

➤Таныш булмаган номердан килгән шалтырату, шикле смс-хәбәрләргә җавап бирмәгез. Анда күрсәтелгән сылтамалар аша керү дә куркыныч икәнен онытмагыз.

➤Банк картагыз, исәп-хисап счетларыгыз турындагы мәгълүматны, телефонга килгән парольләрне таныш булмаган кешеләргә хәбәр итмәгез.

➤Балаларга, өлкән яшьтәге якын кешеләрегезгә кырыгалдарлар һәм аларның алдау ысуллары турында сөйләгез.

➤Алданган очракта, «02» яки «112» номерларына шалтыратып, полициягә хәбәр итегез.

Белгеч сүзе

Регина ФӘХРИСЛАМОВА, педагог-психолог, балалар психологы:

– Балаларны мошенниклар йогынтысыннан саклау өчен, иң беренче чиратта, алар белән гел аралашырга кирәк. 6–9 яшь аралыгында бала тәнкыйди фикер йөртергә өйрәнә. Бу чорда алар бик күп сораулар яудыра. Менә шунда балага яхшылап җавап бирергә, барын да җиренә җиткереп аңлатырга кирәк. «Үскәч аңларсың», «син кечкенә әле» дигән сүзләр булырга тиеш түгел. Юкса бала минем фикерем мөһим түгел дип уйлый башлый. Шуның белән бер рәттән үсмерлек чорына җиткәч инде әти-әнисе дә аңа авторитет булудан туктый. Ул абруйлы затларны читтән эзли башлый. Мошенниклар исә андыйлардан бик оста файдалана.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

КҮРШЕ ХАКЫ

Тавышланмагыз! Россия Дәүләт Думасында ил күләмендә бердәм тынлык вакытын гамәлгә кертергә җыеналар. Закон проекты хуплау тапса, кичке сәгать унбердән алып иртәнге җидегә кадәр генә түгел, ә көндез һәм ялларда да тавышланырга ярамаячак. Югыйсә күрше хакы шактый кыйммәткә төшмәгәе. Тынлык саклый белмәүчеләргә 500 мең сумга кадәр штраф яный. Чүкечле, җыр-көйле, балалы, кыскасы, шаулы күршеләрне закон белән генә акылга утыртып буламы?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Шүрлек бәласе

Әдилә һәм Нияз Закировлар Казандагы яңа торак комплексларның берсендә сатып алган фатирларында ремонт ясый.

– Әллә күрше хакын хаклыйсы, әллә ремонт эшләрен тизрәк бетерәсе, – дип уфтана гаилә башлыгы. – Көндез борау кабызсаң: «Бала йоклый», – дип ишек шакый башлыйлар, шимбә-якшәмбе көнне дырылдатсаң, йортның «Ватсап»тагы төркемендә: «Без тынычлап ял итәргә телибез», – дип су буе язып тутыралар. Ремонт болай да ярты елга сузылды инде. Яңалык гамәлгә керсә, фатирга күчкәнче еллар кирәк булачак. Акча бит ул. Төзелеш материаллары айлап түгел, көнләп арта. Тагын шунысы да бар: мин көндез эштә, ә кич һәм ялларда кулга чүкеч алырга ярамаячак. Болай булгач, шүрлекне кайчан кагасы соң?

Бүген федераль дәрәҗәдә тынлык турындагы закон юк. Бик күпләр, бигрәк тә күпкатлы йортларда, зур юл яки төзелеш янәшәсендә яшәүчеләрнең үзгенә үткән әлеге мәсьәләне һәр төбәк үзе көйли. Мәсәлән, Мәскәүдә – төнге сәгать унбердән иртәнге җидегә кадәр, Санкт-Петербургта – кичке сәгать уннан иртәнге сигезгә кадәр шауларга ярамый. Ә Мәскәү өлкәсендә, төнгесенә өстәп, көндез дә «тынлык сәгате» бар. Татарстанда исә «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында»гы Закон гамәлдә. Аның буенча кичке сәгать уннан иртәнге алтыга кадәр тавышлану тыела. Ял һәм бәйрәм көннәрендә бу кагыйдә иртәнге сәгать тугызга кадәр дәвам итә.

Яңалык хуплау тапкан очракта, ил күләмендә бердәм тынлык вакыты гамәлгә керәчәк. Ягъни кичке сәгать унбердән алып иртәнге җидегә кадәр шауларга ярамаячак. Моннан тыш, ремонтны эш көннәрендә иртәнге сәгать тугыздан кичке җидегә кадәр генә башкарырга рөхсәт итәчәкләр. Әле ул очракта да, көндезге сәгать бердән өчкә кадәр туктап торасы. Аңлашыла инде, соңгысы сабыйларның йокы вакытына туры килә. Ял көннәрендә һәм бәйрәмнәрдә күршеләргә комачау итәрлек бернинди каты тавыш та булырга тиеш түгел, ди закон проектын тәкъдим итүчеләр. Кайбер искәрмәләр дә бар: мәсәлән, Яңа ел төнендә иртәнге сәгать дүрткә кадәр бәйрәм итәргә ярачак.

Закон фатирда гына түгел, ә подъездда, ишегалдында, балалар бакчасы, хастаханә, шифаханә, кунакханә һәм тулай торак тирәсендә шау-гөр килүне дә тыя. Машина сигнализациясе тавышы, мотоцикл гөрелдәве, төзелештәге каты тавышлар, салют-фейерверк, хәтта каты яңгыраган көй дә закон бозу очрагы булып исәпләнәчәк. Яңа кагыйдәләр нигезендә көндез – 55, ә төнлә – 45 дБАдан (тавыш басымы дәрәҗәсе күрсәткече. – **Ред.**) артып киткән теләсә нинди тавыш шаулау булып саналачак. Штраф күләме 500 сумнан 500 мең сумга кадәр җитә. Әниләрне тынычландырып та куйганнар: өйдә бала йөгергән тавыш закон бозуга керми.

Алга китеп булса да әйтик, бу – Дәүләт Думасында тәкъдим ителгән тынлык турындагы закон проектларының беренчесе генә түгел инде. Депутатлар бу уңайдан моңарчы яңгыраган фикерләрне туплап, документны камилләштергән. Шуңа күрә аның яклау табачагына да шик юк.

Ярамыйга карамыймы?

– Әлеге мәсьәлә «көн кадагы»нда тора, – ди «Иҗтимагый фикер – Татарстан» фонды директоры урынбасары Елена Бондаренко. – Еш кына без күршеләрнең ремонт эшләреннән зыян күрүчегә әверeләбез. Бораy яки чүкеч тавышыннан кечкенә балалар йоклый алмый. Ахыр чиктә, үзара мөнәсәбәтләр бозыла, низагны шикаятьләр ярдәмендә хәл итәргә туры килә. Шуңа күрә бөтен ил өчен уртак кагыйдәләр гамәлгә керсә, бер дә начар түгел. Яңа закон күбрәк көндезге «тынлык сәгате»н көйләүгә юнәлдерелгән. Ул сабыйларга да, өлкән яшьтәгеләргә дә тынычлап ял итү мөмкинлеген тәэмин итәчәк.

Ландыш Фазлыева Яшел Үзәндә үз йорты белән яши. Дивар артында терәлеп торган күршеләре булмаса да, барыбер төн йокысы юклыктан зарлана ул.

– Бездән бер йорт аша урнашкан өйдә токымлы этләр үрчетәләр. Аларның тавышы көндез дә, төнлә дә тынгылык бирми, – дип сөйли Ландыш. – Биек койма белән әйләндереп алынган йортта пудель токымлы егермеләп эт бар. Бөтен урамны шаулатып торалар. Ашарга утырсак та, йокларга ятсак та, өйдә эт тавышы. «Тавышланмагыз», – дип күршеләрнең ишеген шакып та, полициягә шалтыратып та туйдык инде. Чарасын күрүче юк. «Этнең авызын бәйләп куеп булмый бит», – диләр. Алар да җан ияләре, янәсе. Тик минем дә тынычлыкта яшисем килә. Яңа закон гамәлгә керсә, зур штрафлардан куркырлар иде, бәлки.

Республикада гамәлдә булган тынлык турындагы закон буенча былтыр күпме кеше административ җаваплылыкка тартылуын белергә теләп, Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәтенә дә шалтыраттык. Тик анда республика буенча мондый исәп-хисап алып барыламы-юкмы дигән сорауга төгәл җавап бирә алмадылар. Уйланырлык җирлек бар, кыскасы.

Алтын урталык кирәк

Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль үзәге башкарма директоры Дмитрий Романов фикеренчә, республикада гамәлдә булган закон да, яңа тәкъдим ителгәне дә бер үк мәсьәләгә килеп төртелә. Ул да булса, иркен яшәргә омтылучы күршеләрнең, урамда шаулашырга яратучыларның тирәюньне ду китергән вакытында әләкләп аласы килү.

– Закон проекты күршеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне көйләү максатыннан эшләнә. Бигрәк тә көндез «тынлык сәгате» урнаштырырга телиләр. Чөнки күпкатлы йортларда яшәүче яшь әниләр арасында: «Көндез бала йоклый алмый», – дип зарланучылар күп. Йә күршедә ремонт бара, йә башкасы дигәндәй. Әмма шул ук дивар бораулаучының тәртип бозуын ничек дәлилләргә соң? Моның өчен өйгә белгеч килеп, тавышны махсус җиһаз ярдәмендә үлчәргә тиеш. Әмма алар шалтыратулар буенча йөрми бит. Штрафны да полиция вәкилләре генә сала. Идарәче оешманың боларның берсенә дә вәкаләт юк. Алар бу эш белән шөгыльләнә дә алмый, – ди ул. – Әйе, закон проекты яклау тапса, бөтен кеше федераль закон бар икәнен белеп торачак. Димәк, тынгысыз күршеләргә дә шуның белән бармак янарга мөмкин булачак. Татарстанда тынлык турындагы закон бар инде. Тик моңа карап кына төн уртасында фатирда футбол уйнарга яратучы күршеләрне бернишләтә алмыйлар. Икенче яктан караганда, һәрнәрсәдән зарланып яшәүчеләр дә байтак. Закон һәркемгә бертигез булырга тиеш дип саныйм.

Белгеч сүзе

Булат ЗАКИРОВ, «ВТ» юристы:

– «Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында»гы республика законын бозучылар административ җаваплылыкка тартыла. Ул кисәтүне дә, административ штраф салуны да күздә тота. Әйтик, гражданнарга 500дән 1000 сумга кадәр штраф яный. Бу хәл бер ел эчендә тагын кабатланса, штраф күләме 1500–2000 сум булырга мөмкин.

ТӨНЛӘ НИ ЭШЛӘРГӘ ЯРАМЫЙ?

✓Төнлә тынлыкны бозуга китергән очракта телевизор, радиоприемник, магнитофон һәм башка тавыш чыгара торган, шул исәптән транспорт чараларында, сәүдә объектларында, җәмгать тукылануы объектларында һәм күңел ачу үзәкләрендә урнаштырылган җайланмаларны куллану;
✓сак сигнализациясен, шул исәптән транспорт чараларында билгеләнгән тавыш сигналларын вакытында сүндермәү, йә төнлә гражданнарның тынычлыгын бозуга китергән төзек булмаган сак сигнализациясен куллану;
✓пиротехник чараларны куллану;
✓музыка инструментларында уйнау, сызгыру, җырлау, шулай ук төнлә тынлыкны бозган тавышлар чыгару;
✓ремонт, төзелеш, төяү-бушату эшләрен башкару.

ТЫЛСЫМ ӘЗЛИ ҖАННАР

ЭЗОТЕРИК КҮРЕНЕШЛӘР БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНУ НИ СӘБӘПЛЕ АРТА?

Сер түгел: акыл белән аңлап һәм аңлатып булмаган күренешләргә җавапны да шундый ук урыннардан эзләргә остардык. Кая барып бәрелергә, кемнән киңәш сорарга белмәгәч, тормышка кайту чарасын багучы, экстрасенс, астролог һәм шул юнәлештә хезмәт күрсәткән башка белгечләрдән сорау киң таралган күренеш хәзер. Статистика да шуны сөйли.

«Бизнесмен ирсез калдым»

...Кулына каләм алганчы, «ВТ» хәбәрчесе иптәш-танышларыннан бу күренешләргә нинди караштa булуларын сорашты. Баксаң, арасыннан берсенә ике тапкыр күрәзәче киләчәк фаразлаган булган икән. Очраклы рәвештә генә!

– Моннан дистә ел элек булган хәл инде бу. Булачак ирем белән очрашып йөргән чак. Казанда дустыбызның туган көненә туган нигезенә җыелдык. Баксаң, әтисенең алдан күрү сәләте бар икән. Һәрхәлдә, шундый даны таралган моның. Бер-бер артлы безне дә тикшереп чыкты. Бушка ич: миңа да киләчәк юрады. Имеш, ике кыз бала табачакмын, ирем кәттә бизнесмен булачак. Егетемне кая куярмын инде болай булгач, дип борчылдым (*көлә*). Бизнесмен ирсез калдым шулай. Балаларыбыз да ике кыз түгел. Бер малай һәм кыз үстерәбез, – дип сөйләде ул. – Алар ышандыра белү сәләтенә ия. Бары шул. Алар – бик әйбәт психологлар. Моннан соң да сәламәтлеккә бәйле рәвештә күрәзәчелек иткәннәре булды. Йөрәгең зәгыйфь, җитди проблемалар булачак, диделәр. Шөкер, сәламәтлегем яхшы.

«Pressfeed» хезмәте, 2021 елдан 2023 елга кадәр россиялеләрнең эзотерика белән кызыксынуы арткан, ди. 2,7 тапкыр! Таролог, нумеролог, астролог, финанс нумерологлары, «җан матрицасы»н ясаучылар, парапсихологлар, багучылар – әнә шундый хезмәтләргә ихтыяҗ зурдан, ди. Тылсым, сихер, фаразлау буенча белем бирү курсларына язылу, 2022 ел белән чагыштырганда, ун мәртәбә арткан.

Хәер, эзотерика һәм астрологиягә ихтыяҗ беркайчан да сүлпән түгел иде. Эзотерика кибетләре хуҗасы, үзе дә сихер-тылсым белән эш итүче Алена Полынь шундый фикердә.

– Сорау һәрвакыт бар иде, ләкин хәзер караш үзгәрде. Мәсәлән, психологларга ихтыяҗ артты. Психология дә тылсым инде ул. Гештальт-терапевт, психолог – бу белгечләр кешеләргә ярдәм итә һәм кешеләр моны аңлады, үзләре үк шул юнәлештә белем ала башлады. Әлбәттә, бу мәйданга төрле кырыгалдарлар, бернинди белеме булмаганнар да чыкты. Кыскасы, ихтыяҗ элеккечә бар, хәзер ул күпкә ачыграк, кешеләр үзләренең астрологиясе, тылсым дөньясын өйрәнүеннән оялмый. Моны, иң беренче чиратта, үз-үзләренә ярдәм итү өчен дип аңлаталар, – дигән фикердә ул. – Әмма бу кызыксынуны баса торган нәрсә бар әле: ул да булса – дини ышанулар.

Алена Полынь фикеренчә, карта белән эш итү, фал ачу аеруча популяр.

– Метафорик карталарны психологлар бик шәп куллана. Бу сеансны МАК-сессия дип атый алар. Ул карталар кызыксыну уятты. Алар үзеңне үстерү, камилләштерү юнәлешендә ярдәм итә. Картаны сатып алучылар күп, – ди Алена Полынь. – Амулетлар димәктән. Кемдер бай булырга, кемдер уңыш казанырга тели. Хатын-кызларны мәхәббәт, ялгызлык темасы аеруча кызыксындыра. Алар яраткан кешесен тартып китерергә тели. Ир-атлар исә акча җәлеп итәргә булышырдай амулетларга кызыга.

Рәхәттән түгел

Казаннан Диләрә Нигъмәтованың үз гомерендә ике тапкыр күрәзәче, өшкерүчеләргә мөрәҗәгать иткәне булган.

– Күз тию дигән нәрсәгә чын күңелдән ышанам. Үземнең дә баштан үтте чөнки, – дип сүз башлады ул. – 2019 елда авырып киттем, бик зур тетрәнүләр башымнан узган ел иде бу. Табиблар диагноз куя алырдай авыру түгел, чөнки авырткан җирем юк, тик йоклый да, юньле-рәтле ашый да алмый башладым. Төшенкелеккә бирелдем, яшәүдә гамь калмады.

Аптырагач, туганнары аңа өшкерүче хәзрәтнең номерын табып бирә. Мактаучылар, аның эшеннән файда күрүчеләр күп икән.

– Алдан ук фикерләремне укыган диярсең, телефоннан ук: «Сеңлем, күз тигән бугай, кил», – диде. Үзем белән гади су алып килергә кушты. Аның янына килгәндә сәгать иртәнге 10нар тирәсе иде. Ара-тирә кешеләр дә бар. Үзем куркам, аягым атлый, дигәндәй. Түргәрәк, ике кеше янына килеп утырдым. Алар да дәва эзләп килгән икән. Берсе Башкортстаннан ук килгән хәтта! Кызын алып килгән. Баксаң, ике ай шушы җирдә йөриләр икән инде. Сәбәбе – кызына җен урнашу. Боларны ишетеп, тагын да куркуга калдым. Әле шул куркуны көчәйтеп, ишегә ябык бер бүлмәдән әллә нинди ят тавышлар ишетелә башлады. Үзенең башына төшмәгән кеше бу хәлләргә ышанмас, ләкин мин бик курыктым. Хәзер миндә дә җен булса дип уйладым. Чират буенча өшкерүче янына кердем. Суны аның өстәле янына куйдым. Ул барысын да



freepik.com

сорашты. Аннары күзләрне йомарга кушты һәм каршыма утырып дога укыды. Күп булса, 10 минут укыгандыр, берара күз алларым караңгыланган кебек булды, аннары тамак төбем кызышты, аннары шул кыз башыма менде, соңыннан барысы да үз халәтенә кайтты. Өшкергән суны алып, хәзрәткә сәдака тапшырып, өйгә кайтып киттем. Юлда кайтканда үз халәтемне аңларга, нәтиҗә ясарга тырыштым. Озак авырудан соң дәвалангандай тойдым үземне (бәлки, үземне артык ышандыргандыр, белмим). Тик шул көннән соң йокым рәтләнде, тамактан ризык үтте. Бәлки, кеше үзен ышандыра гына торгандыр, әмма мин доганың көченә ышандым, – дип сөйләде Диләрә.

Түләгәч, сөйләшәләр

Ихтыяҗ беркайчан да кимемәде, дидек бит инде. Сүзләрнең рас килүенә төшенер өчен, мондый хезмәт тәкъдим итүчеләрне эзләп, игъланнар сайтына күз төшерергә булдык.

Анна карталар белән эшли. Кабул ителәчәк карарларның тормышка ничек тәэсир итәчәген һәм якынча нәтиҗәләрне фаразлый ул. Нумерология белән дә дус.

– Шәхесне энәсеннән җебенә кадәр ачып бирү («распаковка личности» була инде бу. – **Авт.**), мөнәсәбәтләр, карьера, ялгызлык, аерым ситуациягә карталар карашы, шәхеснең тормыштагы миссиясен ачыклау һәм башка сорауларга җавап табарга була, – ди белгеч. – Хезмәтнең хакларына килгәндә, бәяләр 300 сумнан башлана. Шәхесне ачып бирү – иң кыйммәте. 2000 сумга төшәчәк.

«Ходайдан бирелгән күрәзәчелек» иясе Ксения белән исә «WhatsApp» аша аралашырга булдык. Аны интернет аша тапкан идек. Рәсми сайты бар, бик мәгълүматлы, эчтәлекле дип таптык та номерын җыйдык.

Нинди генә ритуаллар ясамый Ксения! Бик көчле догалар да белә, киләчәкне дә фаразлый. Мисал өчен, «Мәхәббәт тылсымы» дигән хезмәтенә ир яисә хатынны гаиләгә кайтару, үзеңә ошаган кешене яраттыру, бозылган мөнәсәбәтләрне җайга салу керә. «Ялгызлык» дигәнендә сөйгәнеңне эзләүдә ярдәм, тизрәк кияүгә чыгу өчен им-том әйтү каралган.

– Консультация-диагностика түләүле. 1 мең сумнан башлана. Консультация барышында тормыш планетагызны карыйбыз, киләчәктә ни буласын һәм нәрсә каласын беләчәкбез, – диде бу. – Акча түләгәч, фото, исем, туган көн һәм елыгыз турында мәгълүмат кирәк булыр.

Алым җәл түгел, гөлем җәл түгел, дигәндәй... Әмма үзен искиткеч көчле күрәзәчелек сәләтенә ия белгеч буларак тәкъдим иткән кешенең «планета» сүзен дә «плонета» дип язуы бу сәләтләрен шик астына куйды. Иртәгәсен уйлап, бүгенгесе белән яшәп торыйк, диде «ВТ» хәбәрчесе.

Фикер

Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ, «Әл-Мәрҗани» мәчете имамы:

– Күрәзәче, экстрасенс, багучыларга йөрүчеләр бар һәм күп. Ни өчен аларга ышаналар? Халык диннән ерагая. Күрәзәчеләр, экстрасенслар белән шайтаннар идарә итә. Шайтанның ялчылары алар. Шайтан кешене беркайчан да туры юлдан йөртмәс. Нинди генә очракта да, кеше диннән чыксын өчен тырышачак. Шайтан бер сүзне дөрес әйтсә, калганнарын бутап әйтер. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кем дә кем багучы янына килеп аннан нидер сораса, аның 40 көн буена намазы кабул булмас», – ди. Әгәр дә шушы кырык көн эчендә бу кеше вафат булса, Аллаһ каршына ул динсез кеше булып барырга мөмкин. Бу күренешне ширек кылуга тиңләргә мөмкин. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер хәдисендә: «Кем сихерчегә һәм багучыга барып, аларга ышана, шул имансызлык белдерә. Кем йолдызлар ярдәмендә күрәзәчелек белән шөгыльләнә, бу кеше сихер юлы белән белем алган була», – дигән.

– Бу кешеләрнең фаразына ышанырга ярамый, ә Коръәндә язылганнарга ышанырга ярый икән, дип каршы килүчеләр дә табылыр. Андыйларга ни диярсез?

22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 «ДЕМОН РЕВОЛЮЦИИ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC
07.00, 12.50, 17.55 Новости
07.05, 12.00, 13.30, 14.10, 14.50, 15.40, 18.00, 21.45 Все на Матч!
10.00 «Лига героев» 12+
11.05 «Универсиада. 10 лет спустя» 12+
12.55 Хоккей 3х3. Международный турнир «Лига Ставок Кубок Будущего»
15.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Зенит» (Санкт-Петербург) – УНИКС (Казань)
18.30 Футбол. МИР РПЛ. «Локомотив» – «Спартак»
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Фиорентина» – «Ювентус»
00.45 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Форталеза» – «Фламенго»
02.30 Новости 0+
02.35 «Вы это видели» 12+
03.00 Бокс. Bare Knuckle FC 16+
04.00 Автоспорт. СМП РСКГ Эндуранс. Кубок России 6+
05.00 Боулинг. Континентальная лига. Про-тур 0+

НТВ

04.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды…» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели…» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «Шоу Аватар» 12+
23.10 «Звезды сошлись» 16+
00.40 «Основано на реальных событиях» 16+
02.35 «СВЕТ И ТЕНЬ МАЯКА» 16+

ДОМАШНИЙ

06.45 «ТЕНЬ ПРОШЛОГО» 16+
10.15 «Уют за 15 минут» 16+
10.30 «СЛЁЗЫ ОСУШИТ ВЕТЕР» 16+
14.50 «ОСТАВЛЕННОЕ СЕРДЦЕ» 16+
19.00 «ЯРКОЕ ПЛАМЯ» 16+
22.50 «Твой Домашний доктор» 16+
23.05 «МОЖЕШЬ МНЕ ВЕРИТЬ» 16+
02.30 «6 кадров» 16+
02.50 «Эффект Матроны» 16+
04.30 «СКАРЛЕТТ» 16+

ЗВЕЗДА

06.00, 02.20 «СКАЗ ПРО ТО, КАК ЦАРЬ ПЕТР АРАПА ЖЕНИЛ» 12+
08.00, 09.15 «ДЕМИДОВЫ» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
11.40, 13.15 «Новороссия» 16+
15.35 «История военной разведки» 16+
19.15 «ОПЕРАЦИЯ «ГОРГОНА» 16+
23.15 «ОЖИДАНИЕ ПОЛКОВНИКА ШАЛЫГИНА» 12+
00.55 «ТАБАЧНЫЙ КАПИТАН» 12+
04.00 «БЕСПОКОЙНОЕ ХОЗЯЙСТВО» 12+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?
Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 30 октябрь

06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Актуаль әңгәмә»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10 «Хәзерге заман әдәбияты үрнәкләре». Айдар Хәлим. Хикәяләр
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Шигърият». Әнәс Хәсәнов әсәрләре
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Җыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 31 октябрь

06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Актуальное интервью»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.10 Прямой эфир
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Күркәм эшләр эзеннән»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты
18.25 Камера музыкасы концерты

Чәршәмбе, 1 ноябрь

06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Юллар чатында»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 «Газиз тавышлар»

Пәнҗешәмбе, 2 ноябрь

06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Перекресток»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Прямой эфир
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «На волне Татарстана»
15.20 «Офыклар»
18.25 Кәрим Тинчурин исемендәге ТДДһК театрында куелган спектакльләрдән җырлар

Җомга, 3 ноябрь

06.00 «Иртәнге нур»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Туры элемтә
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Фидакарьләр» проекты
18.25 Кәрим Тинчурин исемендәге ТДДһК театры артистлары җырлый

Шимбә, 4 ноябрь

08.10 «Уйнагыз, гармуннар!» Әдәби-музыкаль композиция
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Гөлбакча»
10.30 «7 көн»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм»
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Илдар Юзеев. «Кыр казлары артыннан». К. Тинчурин ис. ТДДһК театры спектакле

Якшәмбе, 5 ноябрь

08.10 «Между Волгой и Уралом»
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты. Кәрим Тинчурин исемендәге ТДДһК театры оркестры язмалары
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10, 16.10 Илдар Юзеев. «Кыр казлары артыннан». К. Тинчурин ис. ТДДһК театры спектакле

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы ветераннары (пенсионерлары) төбәк иҗтимагый оешмасы, Әтнә районы ветераннары (пенсионерлары) Советы рәисе (2011–2022 елларда)

ЗИННӘТОВ Мингазиз Зиннәт улының

вафат булуы сәбәпле, балаларының, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Мәрхүмнең урыны оҗмахта булсын, гаиләсенә һәм якыннарына Ходай сабырлык бирсен.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Халык кәефе

Кышка әзерме?

Көнозын диярлек яуган ап-ак карга карап, «ВТ» хәбәрчесе халык кәефен белеште. Сораштыруда катнашучылар кышка әзерме? Көзге соры көннәр аларга ничек тәэсир итә икән?

Булат ХӘСӘНОВ, Теләче районының Алан авыл җирлеге башлыгы:
– Көтүләр керде. Авыл халкы үз көенә яши. Бар да яхшы, зур үзгәрешләр юк. Хуҗалыкта мең баш савым сыеры өчен яңа тораклар, савым заллары төзелә. Халыкны борчыган сорауларны вакытында чишәргә тырышабыз. Мал асраучы хуҗалыклар кышка җитәрлек терлек азыгы туплап, салкыннарга керергә әзер. Көз яңгырлы, пычрак була инде ул – аңа иялэнгән. Ничек бар, шулай кабул итәбез. Табигатьтә начар һава торышы юк, диләрме әле?

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, журналист:
– Шуның хәтле өзелеп көттем бу көннәрне! Сентябрьнең артык җылы килүе, октябрьнең дә гадәттән тыш кояшлы булуы ачуны китерә башлаган иде. Яңгыр көттем. Ул бит әле миңа гына түгел, җиргә дә кирәк. Яңгырлар ява башлагач, кәефләр күтәрелде. Кар бөртекләре күренү тагын да куандырды. Чынлап! Кызым: «Әни, әнә бездә бөтен җир ап-ак», – дип шалтырата. Сизәм: аның да күңеле күтәрелеп киткән. Барысы да урынына кайтты сыман. Без инде өйрәнгән, күрәсең, яңгыр да вакытында явып, җил дә вакытында исүгә. Кар көтсәм дә, әле машина тәгәрмәчләрен алмаштырмадым. Шиномонтажда су буе чират, диләр. Кар яугач, Яңа ел көтә башлыйсың инде. Яңа елда нидер үзгәрер төсле бит әле ул. Ни булса да, яхшыга булып, ил-көннәрдә тынычлык урнашсын иде.

Радик СӘЛАХОВ, көрәшче:
– Сабан туйларыннан соң көрәш сезоны беразга тукталып торса да, үземне формада тотарга тырышам, тренировкаларны калдырмыйм. Әле менә бу атнада Федерация Кубогы – шуңа әзерләнәбез. Кышка, салкыннарга әзер. Ел саен килә торган кыш бит ул (*көлә*). Көтеп алабыз, салкыннарына да иялэнү әллә ни авыр түгел. Соңгы арада тоташ соры, яңгырлы көннәр китте – шул гына бераз кәефне боза.

Айназ ГАБИДУЛЛИНА, блогер:
– Кояш булмау сәбәпле, Д витамины җитмәү сизелә. Мин үземне кояшка, һава торышына бәйлеләр рәтенә кертәм. Иртән тору да авыррак хәзер, ни дә булса эшләргә энтузиазм ташып тормый. Җәй көне бөтен эш тиз башкарыла бит ул: өйне дә ялт кына җыештырып атасың, тегендә дә җитешәсең, монда да барып кайтасың. Ә хәзер, көннәр суыткач, өйдән чыгып киткәнче мең кат уйларга туры килә. Киенәсе, чишенәсе, кулчатыр аласы бар. Әллә машина белән генә барыйммы икән дигән уйлар керә. Ягъни хәрәкәт тә кимеде… Кышны күбрәк көтәм мин. Соры көзге айларны яратып бетермим. Хәер, дөньялар гына тыныч булсын! Бар кайгыбыз шул соры көннәр булса, бер дә зыянлы түгел әле ул.

МАШИНА ЙӨРТҮЧЕ НАЗЫЙМ ГАЛИМОВ:

«ЮЛДА БӨТЕН КЕШЕ ТИГЕЗ»

Йөри белмәгән юл бозар, сөйли белмәгән сүз бозар, ди безнең халык. Октябрьнең соңгы якшәмбесендә Россиядә Автомобильчеләр көне билгеләп үтелә. Шул җәһәттән тәҗрибәле шофер, йөк транспортының төрлесендә йөреп караган Назыйм ГАЛИМОВ белән сөйләштек. Юлда тәртипне кем боза? Озын сәфәргә чыгуның авырлыгы нидә? Акчасына кызыгып кына озын юлларга чыгып буламы?

:: Озын юлга чыкканда иң авыры нәрсә?
– Гаиләм белән аерылышу. Алар белән саубуллашканда, гел бер теләк белән чыгып китәм: яннарына исән-имин әйләнеп кайта алсам ярар иде. Киткән җиреңнән кайта аласыңмы, юкмы – беркем дә кистереп әйтә алмый бит. Башка әнә шундый тискәре уйлар еш килә.

:: Гел ялгызың булу да авырдыр?
– Төрле чаклар була. Берүзең булганда күп уйланасың икән. Өйдән ераккарак киткән саен авыр. Алла сакласын, берәр хәл булып, тиз арада кайтып җитәргә кирәксә, нишлисең? Һәр узган чакрымны кире кайтасы бар. Хәзер инде эшемне алыштырдым, Татарстаннан чыкмыйм диярлек. Сирәк кенә Удмуртиягә чыгып керәм. Гаиләм янында булуны өстен күрәм. Көн дә өйгә кайтудан да рәхәтрәк нәрсә юктыр ул!.. Ләкин юлсыз, рульсез яши алмыйм, шуңа бу өлкәдән китә алмадым.

:: Ерак сәфәрләр вакытында ватылып калган очраклар да буладыр. Андый чакта ярдәм итәләрме? Гомумән, йөк машиналары йөртүчеләр арасында теләктәшлек, дуслык бармы?
– Ерак сәфәрләргә йөри башлаганчы, мин аның асылын бөтенләй аңламаганмын. Ул – үзе бер дөнья. Мәсәлән, фураларда йөрүчеләр рация ярдәмендә аралаша бит инде. Алда «бөке», юл һәлакәте һәм башка тоткарлыклар булa калса, арттарак баручылар моны белеп тора. Ярдәм кирәк чакта да шул рация аша хәбәр итәргә була. Мин эшләгән бер оешмада шундый тәртип бар иде: берәү ватылып туктый икән, җитәкчегә хәбәр итә. Җитәкче исә якын-тирәдәгеләргә туктарга куша. Туктамыйча узып киткән очракта зур гына штраф язалар иде. Билгеле, штрафы булмаса да, мөмкинлегеңә карап, иптәшеңә булышырга ничек тә туктыйсың инде.

Йөк машинасында йөрү белән җиңел машинада йөрү – икесе ике нәрсә. Әйтик, җиңел машина фураны кистереп, я булмаса нindидер начарлык эшләп китә ала. Газына басса, кайсы фура артыннан чаба алсын инде аның?! Өстәвенә тизлекне чикли торган җайланма торганда. Ә бер фура йөртүче икенчесенә шундый начарлык эшләсә, качып котылып булмый. Ике яктан «кысасылар», туктап беткәнеңне сизми каласың. Җитмәсә, син хезмәттәшләрең белән гел элемтәдә. Кыскасы, дорфаланып, кыланып йөрүдән файда юк.

:: Димәк, тәртипне ешрак җиңел машиналар боза?
– Җиңел машина йөртүчеләр белән фура йөртүчеләр арасында киеренке мөнәсәбәтләр электән бар инде ул. Әйтик, зур машиналар «бөке»дә тәртип белән генә тезеләләр дә сабыр гына утыралар. Ә җиңел машина йөртүчеләр я уңнан, я сулдан узып китәргә тырыша. Әйтерсең, алар гына ашыга, аларга гына каядыр барып җитәргә кирәк! Юлда бөтен кеше тигез. Берәү дә олы юлга табигать белән хозурланып утырыр өчен чыкмый. Ул оятсыз машина йөртүчеләр көнкүрештә яшәеш өчен кирәк булган бөтен товарны фуралар ташыганын, алар ташый торган йөкнең ни дәрәҗәдә кыйммәтле булуын аңларга теләми шул. Кистерәләр, авария үк ясамасалар да, нерв күзәнәкләреңне тынычлыгын бозалар.

:: Тәртип, димәктән. Хәзерге кадәр юл төзелеше булган чакны хәтерлисезме?
– Россиядә юллар гел төзелә инде ул. Нинди киң, нинди шәп безнең юллар, ләкин ремонт тукталып тормый, яңалары да төзелеп тора. Әле менә «М12»нең картасын ачып караган идем, күпләр өчен бик файдалы проект буласы, ахры.

:: Йөк машиналары йөртүчеләр арасында яшьләр күпме?
– Реклама шәп эшли бу өлкәдә. «Хезмәт хакы 200 мең сумнан башлана» кебек эчтәлектәге реклама язуларының чуты юк бит хәзер. Кызыгып киләләр дә, чынбарлыкны күргәч, китәләр. Мин эшләгән бер оешмада көненә 100 кеше килеп, 100 кеше китә иде.

Әзерлекне бик тәфсилләп тикшерәләр. Һәрхәлдә, мин фура йөртергә эшкә кергәндә шулай иде. Синең фурада йөри белү-белмәвеңне сорау бирепт тә аңышалар. Аннан инде рульгә утыртып тикшерәләр. Биремнәрне үтәргә өч мөмкинлек бирелә. Өч тапкыр да булдыра алмыйсың икән, «Энем, ишек тегe якта», – диләр дә вәссәлам.

:: Сез бит инде күпсанлы шәһәрләр аша узасыз. Яңа шәһәргә баргач, туктап, моңарчы күрмәгән урыннарны күрәсе киләме?
– Әлбәттә. Йөргән саен кызыксынасың. Кайвакыт йөк алырга барган шәһәрдә бер-ике көн торырга туры килә. Андый чакта кабинада утырып булмый бит инде. Кесәңнең калынлыгына карап, бераз сәяхәт итәсең. Андый чакта гел, монда тагын кайчан килермен, дип уйлыйм да мөмкинлектән файдаланырга тырышам. Әйтик, гомеремдә беренче тапкыр Мурманск шәһәренә барырга туры килде. Анда да ак төннәр чорына эләктем. Гаҗәеп күренеш инде менә! Мурманскига калган гомеремдә әллә бара алам мин, әллә юк…

:: Юл җене кагылган, дип әйтеп буламы сезнең турында? Һәрхәлдә, хезмәт хакына гына кызыгып утырмыйсыздыр кебек рульгә...
– Кечкенәдән техникага тартылдым. Укырга кергәнче үк әтинең тракторына утырып йөрдем. Өч абыем бар, өчесе дә – шоферлар. 6–7 нче сыйныфларда укыганда, печәнгә төшкәч, олы абыем «КамАЗ»ын йөртеп карарга бирә иде. Андый бәхет бөтен кешегә дә тәтеми иде ул чакта. Аны кабызып, 5 метр булса да йөреп, үзең сүндерә алсаң, геройга тиң буласың, билләһи. Техникадан килә торган искә кадәр кадерле. Ягулык, төтен, резин исе. Әйтерсең, җаныңнан килә ул ис…

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

ОНЫТЫЛА ЯЗГАН ҺӘЙКӘЛЛӘР

Башкалабызның һәр карыш җире төрле чордагы вакыйгаларга бәйле. Археологлар эзләнә, тарих битләре көннән-көн ачыла бара. Әмма без күп вакытта батыр яугирләребез рухына дога кылырлык урыннарны бөтенләй белмибез кебек. Әллә алар юкмы?



Шул сорау белән тарих фәннәре докторы, археолог Фаяз ХУҖИНга мөрәҗәгать иттек.

:: Фаяз Шәрипович, археологлар Кремль территориясендә шактый гына казу эшләре алып бардылар. Бабаларыбыз тарихына кагылышлы һәйкәлләргә дә юлыкмый калмаганнардыр?

– Бар андый һәйкәлләр. Тик алар турында, чыннан да, халык бик аз белә шул. Читтән килгән туристларга да күрсәтмиләр ул урыннарны. Мин иң әүвәл хәзерге Благовещение соборы каршындагы бакчада табылган атаклы Колшәриф мәчете хәрабәләрен күз алдында тотам. Без аны 1990 нчы еллар ахырында казып тикшергән идек. Ак таштан салынган зур гына комплекс ул, мәчет янында ук мәдрәсәсе дә булган. Тик начар сакланган. Аны 1840 нчы елларда шул тирәдә генә төзелә башлаган Архиерей йортын салганда җимереп бетерәләр. Аннан соң ул бинаның, мәчетнең бер өлешен генә ача алдык бит әле, чөнки мөмкинлек булмады, асфальт юл астында калган ул. Менә шул казылган өлешен генә булса да консервация ысулы белән саклап калырга, экскурсиягә килгән кешеләргә күрсәтерлек дәрәҗәгә җиткерергә була иде югыйсә. Хәрабәләрне күмеп куярга куштылар. Минемчә, бу тарихи истәлеккә яңадан әйләнеп кайтырга кирәк. Ә бүген ул урынга вакытлыча истәлек тактасы куеп була. Тарихи Колшәриф мәчетенең кайда урнашканлыгын халык белеп торсын. Кремль калкулыгының иң биек ноктасында ул.

:: Кремльнең хәзер Тайницкая дип атала торган башнясы янында ниндидер яшерен чишмә булган дип сөйләгәннәрен ишеткәнем бар. Башняның исеме дә шул чишмәгә бәйле бугай.

– Ул чишмә турында билгесез автор тарафыннан 1564–1565 елларда язылган «Казан тарихы» китабында да, кайбер рус елъязмаларында да телгә алына. Имеш, бу чишмә рус баскынчылары һөҗүме алдыннан Кремль стеналары эченә кереп яшеренгән шәһәр халкының бердәнбер су чыганагы булган. Шул чишмәгә Нурали (хәзерге Тайницкая) башнясы астыннан яшерен җир асты юлы алып барган. Әмма Казан ягыннан Камай морза исемле бер сатлыкҗан ул чишмә турындагы серне Явыз Иванга сөйләп бирә. Дошман яугирләре чишмәне шартлатып җимерәләр. Халык сусызлыктан интегә. Елъязмаларга теркәлеп калган әлеге хәбәрләр чынбарлыкка охшаган. Шуңа күрә узган гасыр урталарында археолог Николай Калинин Нурали башнясы эчендәге яшерен җир асты юлын табарга тырышып караган, әмма уңышсызлыкка очраган. 2000 елда безгә дә Кремль калкулыгының Казансу ягындагы битендә, Тайницкая башнясыннан 30–35 метр көнчыгышкарак китеп, казу эшләре алып барырга туры килде. Биш метр чамасы тирәнлектә су чыга башлагач, шатланган идек тә, тик ул янәшәдәге елга суы булып чыкты. Бу чишмәгә әле XX гасыр башларына кадәр, хәтта соңрак та Казан халкы су алырга йөргән. Суы йомшак, тәмле булган чөнки. Музей-тыюлык җитәкчеләренә без шул тирәдә матур гына бер чишмә ясап куярга тәкъдим иткән идек. Хупламадылар. Минемчә, ул идеягә әйләнеп кайтырга хәзер дә соң түгел әле. Исемен дә «Серле чишмә» дип атарга була. Халык күп йөри бу тирәгә. Якында гына без казып чыгарган һәм нәкъ менә Казанны яулап алу алдыннан төзелә башлаган Төньяк башнясы да урнашкан бит. Ул – ханлык чорына караган бердәнбер таш ныгытма.

:: Бер тарихи китапта 1552 ел вакыйгаларына бәйле рәвештә телгә алынган «Даир мунчасы» турында укыган идем. Таһир мунчасыдыр инде ул. Кай тирәдәрәк булган икән?

– Таһир мунчасы, елъязмаларда искәртеп үтелгәнчә, Болак елгасының уң ягында, Нурали башнясыннан ерак булмаган бер җирдә урнашкан булган. Елъязмаларда, шул башняны шартлату өчен, дары тутырылган мичкәләрне нәкъ менә Таһир мунчасыннан башланып киткән җир асты юлыннан ташыганнар, дип әйтелә. Нурали башнясын 4 сентябрьдә шартлатып җимерәләр. Шул тирәдәрәк, хәзерге цирк бинасы каршында, без казу эшләре үткәреп караган идек. Хәтта монголлар чорына кадәрге табылдыклар да килеп чыкты, әмма борынгы бина эзләре сакланмаган. Юкка чыккан инде алар. Шулай да, минемчә, без фаразлаган урында кыскача гына тарихи мәгълүматлар язылган истәлек билгесе куярга була. Алай гына да түгел, хәтта таштан мунча бинасын да төзеп куярга кирәктер, бәлки. Яхшы гына сакланган Биләр-Болгар мунчалары билгеле бит. Ханлык чорындагылары да архитектурасы ягыннан элеккеләреннән әллә ни аерылып тормаганнардыр дип уйлыйм.

:: Казанның төп халкы, башлыча һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр, Кремль тирәсендәге бистәләрдә яшәгән. Ул бистәләрнең ныгытмалары булган. Алар археологлар тарафыннан өйрәнелгәнме?

– Рус елъязмаларындагы мәгълүматларга караганда, бистәләрнең саклану ныгытмалары булган, әмма алар бик начар өйрәнелгән. Казып карадык, әлбәттә, төзелеш эшләре вакытында да даими күзәтүләр алып барабыз. Әмма нәтиҗәләр канәгатьләнерлек түгел. Бу аңлашыла да: башкалабызның борынгы чорларга караган үзәк өлеше нык җимерелгән. Табылдыклар очрап тора, әмма торак йорт, хуҗалык, һөнәрчелек һәм хәрби ныгытма корылмалары сакланмаган. Шунысы куандыра: ханлык чорыннан калган бистә ныгытмалары, дөресрәге, агач диварлар, аларның капкалары һәм башнялары, бөтенләй җимерек хәлдә булса да, әле XVIII йөзгә кадәр күренеп торган. Ә ул башняларның исемнәре – Хан, Арча, Ногай, Көрәеш, Аталык капкалары – XVI гасырга караган язмаларда сакланган. Менә шул язмаларны чагыштырып өйрәнгәннән соң, капкалы башняларның урыннарын бүгенге Казан картасында ярыйсы гына төгәл күрсәтә алабыз. Әйткәнемчә, аларның эзләре сакланмаган, әмма шулай да фаразлана торган урыннарга истәлек билгеләре куярга була, минемчә.



«Татар-информ»

Фаяз Хуҗин әйтүенчә, соңгы елларда Сөембикә манарасы XVII–XVIII гасырлар чигендә барлыкка килгән, дип расларлык материаллар табылган.

:: 1552 ел вакыйгаларына бәйле тарих-археология истәлекләре турында сөйләгәндә, сез нишләптер Сөембикә манарасын телгә алмадыгыз.

– Без, археологлар, аны ханлык чоры истәлеге дип танымыйбыз. Соңгы елларда Сөембикә манарасы XVII–XVIII гасырлар чигендә барлыкка килгән, дип расларлык материаллар табылды. Манараның төньяк-көнчыгыш почмагы элгәреге Хан мәчете өстенә туры килә. Сөембикә исемен телгә алгач, форсаттан файдаланып, бүгенге әңгәмә темасына туры килә торган тагын бер тәкъдимемне әйтеп үтәсем килә. Башкалар тарафыннан күптән әйтелгән фикер инде ул, әмма нишләптер җитәкчеләр тарафыннан һаман да игътибарга алынмый.

> Сүз – Казан үзәгендәге Бауман урамы исемен үзебезнең милли каһарманнар Колшәриф яисә Сөембикә исемнәренә алыштыру зарурлыгы турында. Алай гына да түгел, әлеге тарихи шәхесләрнең исемен һәйкәлләрдә дә мәңгеләштерергә кирәк, минемчә.

Киләчәктә әле скульпторларыбыз Казан ханнарының гомумиләштерелгән образын да тудырырлар, 1552 елда һәлак булган каһарманнарыбызны да онытмаслар, дип өметләнәм.

Бу теләкләр, тәкъдимнәр, аларны тормышка ашыру туристлар санын арттыру өчен генә түгел, үзебезнең киләчәгебез өчен, яшь буынны милләтпәрвәрләр итеп тәрбияләү өчен кирәк.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сәрия
МИФТАХОВА

ДӨРЕС ЮЛ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Шатлыклы хәбәр

Гомер буе фермада сыер сауган ул. Моңа кадәр «Ана даны» ордены, башка медальләр белән бүләкләнгән. Ә бу юлы – тагын да зуррагы. Гап-гади, тыйнак авыл апаен шулай олыласыннар әле. Әлеге хәбәрне ишеткәч, Наилә ханым аптырап калган.

– Сөендем инде, ничек сөенмисең ди?! Барлык кешегә дә бирелә торган бүләк түгел бит. Ун баланы лаеклы итеп үстергәч, герой була торганмыңдыр инде. Бик бәхетле әни мин. Балаларыбыз беркайчан да йөзебезгә кызыллык китермәде. Ул-кызларымның барысы да үз гаиләсен корды. Ранил улым гына әлегә өйләнмәгән. Бик бай әби мин: 18 оныгым, бер онықчыгым бар, – ди Наилә апа. – Бүләкнең кайчан тапшырыласын әлегә әйтмәделәр. Мәскәүгә кадәр бара алырмынмы икән? Сәламәтлек чамалы хәзер.

Кариле авылында яшәп, үзе дә өч бала тәрбияләүче Лилия Саттарова да әнисен «Герой ана» исеме белән зурлауларына сөенә.

– Бу бүләк әнигә ун бала тапканга яки сыер сауганга гына түгел, безне лаеклы итеп үстергән өчен бирелә. Димәк, бирерлеге бар. Путин карарга кул куйган икән, димәк, әниебез моңа лаек. Медаль бирмәсәләр дә, ул безнең өчен күптән герой инде, – ди ул. – Безнең әни һәрвакыт таләпчән булды. Кечкенә чакта бер генә эшне дә ярты юлда калдырырга рөхсәт итмәде. Калган эшкә кар ява, дип өйрәтте. «Хезмәтегез минем өчен булса, өйрәнгәнегез – үзегезгә», – дип кабатлады. Тормышта да әнинең киңәшләрен истә тотам. Җор телле булуы, беркайчан да моңаеп утырмавы белән дә үрнәк ул миңа.

Галиевлар гаиләсендә 1974 елда беренче бала булып кызлары Гөлназ туа. 1977 елда Рәмзия дөньяга килә. Анналары уллары Рөстәм, Фәнис, Алмаз туа. 1986 елда уллары Рәмисне алып кайталар. 1988дә – Лилия, 1991дә – Ранил, 1993тә – Алинә, 1996да Рамил туа.

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, республикада күпбалалы 42707 гаилә бар. Аларда 135817 бала тәрбияләнә.

3 балалы гаиләләр	37023
4 балалы гаиләләр	4203
5 балалы гаиләләр	1106
6 балалы гаиләләр	262
7 балалы гаиләләр	80
8 балалы гаиләләр	25
9 балалы гаиләләр	6
10 балалы гаиләләр	2

КҮПБАЛАЛЫ ГАИЛӘЛӘР

Казанда	11294
Чаллыда	4636
Түбән Камада	3191
Әлмәттә	2029
Яшел Үзәндә	1469
Алабугада	1243
Биектауда	1039
Бөгелмәдә	977
Лаешта	973
Чистайда	932

Галиевларның шәхси архивыннан

Наилә апа 10 баласы, 18 оныгы, бер онықчыгына сөенеп яши.

Авылны саклаучылар

Харис абый белән Наилә ханым алты ул, дүрт кыз тәрбияләгән. Гаилә башлыгы җиде ел элек дөнья куйган. Төпчек улы Рамил, килене Илүзә гаиләсе белән яши Герой ана. Әле өйләнмәгән улы Ранил дә янәшәсендә. Олысы – Рөстәме, укып бетергәч, Әлмәткә нефть юнәлеше буенча китсә, калганнары барысы да Норма авыл җирлегендә төпләнгән. Һәркайсының – үз шөгыле. Әйтик, Рамил җиһазлар ясау белән шөгыльләнә. Рәмис такта ярдыру цехы ачкан.

– Әти сүзе бер була. Ул тракторчы иде. Чын җир кешесе. «Шәһәрдә сезне беркем дә көтеп тормый, авылда калыгыз», – ди иде. Авылда рәхәт бит. Шәһәрдән ким яшәмибез, – ди 27 яшьлек Рамил. – Туган нигез гөрләп тора. Хәзер бит күршегә йөрү гадәте, туганлык хисләре бетеп бара. Шөкер, бездә алай түгел. Туганнарым бәйрәм саен туган нигезгә җыела. Бездә билгеләп үтәргә туган көннәр дә күп бит. Чәй эчеп, гармун тартып, җырлашып утырабыз.

Норма авыл җирлеге башлыгы Радик Шәрипҗанов, кая гына барса да, үрнәк итеп Галиевларны мисалга китерә.

– Наилә апаның ун баласы да авылда төпләнгән дияргә мөмкин. Рөстәм дә прописскада авылда. Монда йорт салды. Пенсиягә чыккач, кайтырга исәбе. Наилә апаның уллары барысы да йорт җиткезде. Авылдан китмәү, аны таркатмау – зур нәрсә. Галиевлар тәртипле, эшчән. Берсе дә кемнәндер ярдәм өмет итеп яшәми. Авылда эш юк дип зарлану бер дә дөрес түгел. Эш бар ул. Җирне, туган якны ярата торган бала тәрбияләү әти-әнидән тора, – ди җирлек башлыгы.

Тәрбия ул кәнфит бирү генә түгел

Харис абый улларын – җир эшенә, Наилә апа исә кызларын өйдәгесен тәртипләргә өйрәткән. Эш бүлешү дигән нәрсә булмаган, барысын да бергә эшләгәннәр. Уллары «хатын-кыз эше бит бу» дип карышып тормаган, идәнен дә, табак-савытын да юган, хәзер дә юалар икән. Наилә апа балаларны кечкенәдән хезмәткә өйрәтергә кирәк дип саный. «Кеше әйберенә кызыкмагыз, үзегез тир түгеп алыгыз!», «Әтиегездән сорагыз!» Менә шул сүзләрне еш кабатлаган ул. Балалар каеш тәрбиясе дигән нәрсәне белмәгән. Ачуланып та, иркәләп тә үстермәгәннәр, кыскасы. Харис абыйның кулында гармун булса, Наилә апа бик матур итеп җырлаган. Бу моң, сәләт балаларына да күчкән.

– «Шуның кадәр баланы ничек тәрбияләп бетердегез?» – дигән сорауны әнигә еш бирәбез. Хәзер бит бер-икене үстерү өчен дә зур көч кирәк. Безнең әни тыйнак, сабыр ул. Беркайчан да кызып китми. Югыйсә ун баланы тәрбияли алмас иде. Ачулана белми. Бер-беребезне карашырга да булыша идек. Төпчек булгач, миңа наз, игътибар күбрәк эләкте. Тәрбиябездә әтинең дә роле зур. Уен-көлке ярата иде ул, – ди Рамил.

Наилә апа әйтүенчә, бала үстергәндәге авырлыкларның күбесе онытылган инде. Әмма кайберләре барыбер искә төшә икән әле.

– Безнең заманда пособиеләр юк иде. Киемгә, бала чүпрәкләренә кытлык булды. Колготкины да кибеттә гаиләгә бары икешәрне генә бирәләр иде. Акча юк дип тормадык, гаиләне ишәйттек тә ишәйттек. Хәзер инде бала үстерү өчен бөтен нәрсә бар. Бала табарга куркырга кирәкми. Рәхәтләрен тоеп яшим. Берсенең дә авыр сүз әйткәне юк. Бәйрәмнәр җитсә, тизрәк бүләкләрен күтәреп, әни дип килеп җитәләр. Хәлемне белешеп торалар. Алга таба да туры юлдан гына барсыннар. Ил-көннәребез тыныч булсын, – ди Герой ана.

Белешмә



«Герой ана» исеме СССРда 1944 елда бирелә башлый. Бу исемгә 10 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләп үстергән 400 меңнән артык хатын-кыз лаек була. Россия Президенты Владимир Путин «Герой ана» исемен гамәлгә кертү турындагы карарны узган елның августында имзалады.

АЙДАР ФӘЙЗРАХМАНОВ:
«СӘХНӘНЕ ЧҮП БАСТЫ»



Әдәбият-сәнгатьтә югалтулар күбрәкме, табышлармы? Илкөндәге вазгыять иҗатка ничек тәэсир итә? Үзешчәнлек алга чыккан заманда профессионаллар ничек яши? Бу сорауларга җавапны Татарстан фольклор музыкасы дәүләт ансамбле һәм Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе сәнгать җитәкчесе Айдар ФӘЙЗРАХМАНОВ белән эзләдек.

:: Үзегез өчен иң рәхәт чор дип кайсы вакытны әйтер идегез?

– Үткән гомергә борылып карасак, аның һәрбер чоры матур, рәхәт узган. Кеше күңеле шулай корылгандыр, анда матур вакыйгалар гына сакланып кала, авырлыгы истә калмый. Һәрхәлдә, минем күңелем шундый. Балачак. Ул вакытта да авырлыклар хәттин ашкан. Арчага менеп, бер буханка ипи алыр өчен, чиратта сытылып беткән малайлар без. Юлда аның яртысын ашап та бетерә идек инде. Ул бер моңсу хатирә булып кына искә төшә, авырлык түгел. Яшүсмер чак. Сирень чәчәк атканда, гармун күтәреп җырлап урам әйләнүләр. Яшьләр безнең капка төбенә җыела, минем кайтканлыкны белеп көтәләр. Рәхәт чак. Студент еллары. Ул вакыттагы белем чын мәгънәсендәге белем иде. Мин музыка факультетына иртәнге алтыда торып китә идем. Андагы чардак минеке. Баскыч төбендә ике квадрат метрлы гына урын бар, анда урындыгым тора. Шунда баянда шөгыльләнергә кереп утырам. Башлы-күзле булу, гаилә кору, балалар туу – нинди матур чаклар! Әмма ул чорның да авырлыклары булган. Талонга корылган заман, мин төшкә өйгә йөгереп кайтам, балалар янында калам, ә Халисә талонга ипи сөт алырга йөгереп чыгып китә. Ике бала, зур сумкалар асып, электричкада кайтулар, Арчага җәяү менүләр, аннары 4 чакрым тәпиләп Урта Бирәзә авылына кайтулар. Авылдагы бөтен эш сиңа өелгән: бәрәңге утырту, алу, җир эшкәртү. Авыр, әмма матур вакытлар. Берсен дә кире кайтарып булмый, бәлкем шунысы белән дә алар шулкадәр кадерледер. Театрда эшләү, эстрада сәнгате… Ул чор сәнгате бөтенләй икенче төрле, анда бар нәрсә матурлыкка, иҗатка корылган иде. Хәзерге чор үзенчә матур. Яшьләр белән эшлим, иҗатның да, тормышның да тукталганы юк. Әле алга таба да әллә күпме идеяләр бар.

> Елына бер-ике җыр яздыра ала идек яздырсак. Радиога язылырга ике айлап алдан вакыт алып куярга кирәк. Ул чакта техника әллә ни мөмкинлекләр бирми, һәр нотаңны тиешле дәрәҗәгә күтәреп утырмый – баштан азакка хәтле җырлап чыгасың да, шул язмалар фондка кереп тә кала. 1986 елда язылган «Су буеннан әнкәй кайтып килә», «Мин сине шундый сагындым» – бер тапкыр җырлап яздырылган җырлар. Бер тапкыр җырлап чыгар өчен әзерлек 1–1,5 ай вакытны ала иде.

:: Әдәбият-мәдәнияттәге бүгенге хәлебезне артка чигенү дип әйтеп буламы?

– Җырчы нинди вазгыятьтә тәрбияләнә, җырында шул була. Халык аны оясында ни күрсә… дип тә әйтә. Бу җәһәттән борчыган мәсьәләләр шактый. Аларның иң төпгесе – үткән дәвер шагыйрьләре, композиторлары, җырчылары калдырган мираска сакчыл карамау. Ә бит еш кына әсәрне танымаслык дәрәҗәгә җиткерәләр. Безнең аны үзгәртергә хакыбыз юк. Үзгәрткәндә дә, мәгънәдән, мелодикадан, гармониядән тайпылырга ярамый. Яшьләр башкаруында татар халык җырларын тыңлаганда, кәеф кырыла. Сүзләре дөрес түгел. Бу даими рәвештә бара. Чөнки аңламыйлар, чөнки тел китә… Өметле яшьләр бик күп, әмма замана җилбәзәклегенә бирелаләр. Нәтиҗәдә кыйбла югала. Кыйбланы югалтмас өчен, фәлсәфә сату гына бик аз, эшләп күрсәтергә кирәк. Мин үз эшемне фольклор музыкасы дәүләт ансамблендә алып барам. Монда иҗат, мирасны пропагандалау һәм халыкка җиткерү беренче планда. Бу эштә без Мәдәният, Мәгариф министрлыклары, Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан теләктәшлек табабыз. Әмма бу эш кенә аз, тагын да колачлырак эшләргә кирәк. Чит илләрдә безгә мөнәсәбәт бик яхшы, әмма үзебездә бу эштә, гомумән, профессиональ сәнгатьтә пропаганда зур дип әйтеп булмый. Ә нәрсәне пропагандалыйбыз без? Шоу, шау-шу, юк-бар сүз, гайбәт. Ул башта интернетка килеп керде, хәзер инде матбугат та шушы чирне эләктерде. Кемгә кирәк ул кемнәрнеңдер өйләнешүе, аерылышуы? Нишләп шәхесләр, борчыган мәсьәләләр турында язылмый? Чөнки сүз дә акча бизмәнендә үлчәнә башлады. Бу инде халыкка иярүгә китереп җиткерде, тәрбия югалды.

Мин сәхнәдән беркайчан да тозсыз сүз, анекдот сөйләмәдем. Чөнки сәхнә ул мунча ләүкәсе түгел, ул – тәхет.

:: Мәсьәләне ничек хәл итәргә соң? Сәхнәнең дәрәҗәсен ничек кайтарырга?

– Элек сәнгать советлары бар иде, алар сәхнәнең дәрәҗәсен саклады. Хәзер әлеге органны кире кайтарсак, эстраданың 80 процентына каршы төшәчәкбез, димәк, табышны югалтабыз дигән сүз. Шуңа күрә эстрада үз агымында бара булса кирәк. Мин бу хакта бик күп уйланам, чагыштырырга тырышам. Әле менә ансамбль белән Төрекмәнстанда булып кайттык. Телевидение каналларында анда да башбаштаклык. Юкса бит дин дә, ден дә алда бара торган республика. Телевидениесендә исә шул ук шәрә кызлар, тәртипсезлек һәм аһәңнең бозылуы. Чечня Республикасында исә мондый нәрсә юк.

Икенче борчыган нәрсә – белем дәрәҗәсе. Инде хәзер укытучылар да ярымпрофессионаллар, тәҗрибәләре дә юк. Кеше югары белем алып, шул юнәлештә 10–15 ел эшләгәннән соң гына тәҗрибә туплый. Мин ни өчен музыка факультетында кафедраны 15 ел җитәкләгәннән соң, аннан китәргә булдым? Чөнки кадрлар килмәде. Ансамбльгә исә балалар килә, мондә аз гына тәҗрибә туплап, белем алганнан соң, акча эшләргә дип, эстрадага китә башлады. Миннән хәзер егермеләп кеше китеп, үз көннәрен күрә. Ярый хуш, шулай булсын. Әмма профессиональ сәхнә, профессиональ белем дигән юнәлеш юкка чыкты – менә шуңа эч поша. Сәхнәгә, ташкын булып, үзешчән сәнгать һәм тамадалар килеп керде. Хәзерге популяр җырчылар – тамадалар. Хәзер төзүче дә, укытучы да, журналист та – теләге булган һәр кеше җырчы. Әле без аларга атказанган дигән мактаулы исем дә бирәбез. Юкса «атказанган артист» дигән исем профессиональ белеме булган кешеләргә генә бирелергә тиеш. Ансамбльдә, мәсәлән, атказанган исемен алу өчен артистның 10 еллап эшләве кирәк. Әле аннан соң да бу исем җиңел бирелми. Әйтик, менә мин авылда 20 ел бәрәңге үстердем. Әмма нишләптер беркем дә «атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән исем бирмәде. Эш бит исем бирүдә генә түгел.

:: Профессиональ сәнгатьтә эстрадага караганда исем алу авыррак, акчасы азрак булып чыгамы?

– Менә шуңа профессиональ сәнгать саекканнан-саега да инде. Монда эшкә чын күңелдән бирелгәннәр генә кала.

:: Сәнгатьтә югалтулар күбрәк, димәк?

– Мин элеккеге язмаларны да күп тыңлыйм, хәзерге заман җырчыларының иҗатларын да күзәтеп барырга

тырышам. Артка тәгәрәдек дип әйтә алмыйм. Әйбәт җырчыларыбыз да, әйбәт җырларыбыз да бар. Бүген музыкаль театр ачу мәсьәләсен күтәрәбез. Әгәр музыкаль мирасны саклау юнәлешендә эшләячәк икән, булсын гына. Минә минем ике музыкаль белемем бар, утыз елдан артык эш тәҗрибәм дә бар. Әмма музыка өлкәсендәге кайбер юнәлешләрне мин дә аңлый алмыйм. Кайбер музыка әсәрләрен дә аңламыйм. Профессиональ музыкантлар язган кайбер әсәрләрдә милли аһәң дә ишетмим. Аны дөнья күләмендә танылды дип сөйләсәләр, бервакытта да ышанмыйм, акыят сөйләмәгез. Бах, Бетховен дәрәҗәсендә булса ясә Нәҗип Җиһанов, Фәрит Яруллин, Сәйдәшев дәрәҗәсендә булса, дөнья күләменә чыга алуына әле ышаныр идем. Сүз уңаеннан шунысын да әйтим: әле телгә алган олы шәхесләрне дә оныттык бит. Без оныткач, мәктәп балалары каян белсен аны? Татарстан мәктәпләрендә чыгыш ясаганда, балалардан кайсы композиторларны белүләрен сорагач, алар Фирзәр Мортазинны әйтергә мөмкин әле, классикларны белми дә белми инде... Әллә нигә бер, туган яки үлгән көннәрендә Илһам Шакировны, Әлфия Авзалованы искә алабыз. Безнең бит олпат шәхесләребез бар әле! Алар бүген бар, иртәгә юк. Нишләп аларны күрмибез? Бик кызганыч, менә бу агым профессиональ җырчыларга да тәэсир итә, алар да шул шаукымга иярә. Нәтиҗәдә репертуарлары ваклана.

> Уфада гастрольдә чакта Равил Гайнетдин, сәхнә артына кереп: «Сез дин тыелган заманнарда милләтне саклап калдыгыз, рәхмәт сезгә», – дип әйткән иде. Хәзер дин ныгып китте, ә сәнгать өлкәсен чүп басты. Дингә чүп керә алмый. Аны Корьән кануннары саклый. Сәнгатьне боза да, сыза да, юкка чыгара да алалар. Бәлкем бу өлкәне дә кануни рәвештә тәртипкә салырга кирәктер.

:: Рөстәм Мингалим иҗатын яратасызмы? Гомумән, татар сүзенә ихтыяҗ бармы?

– Рөстәм Мингалим иҗатын гына түгел, Роберт Әхмәтҗанов, Кадыйр Сибгатуллин, Равил Фәйзуллин иҗатларын да яратам. Мин алар белән яшь чакта аралаша идем. Роберт абыйның китабын бүләк итеп киткәне дә бар. Ул чорда әле мин аларның иҗатын аңларга әзер түгел идем. Аларның иҗатын аңларга мин 60–65 яшьләремдә өлгереп җиттем. Шуннан шушы шагыйрьләрнең иҗатына багышланган «Олы юл әйтте» дигән цикл башлапкитте. Мин, беләсеңме, нәрсәгә шатланам: ул цикл үзенең җимешләрен дә бирде. Татар сүзенең татар дөньясына әйләнеп кайтуын мин шушы циклның файдасы дип кабул иттем. Бу концертларны күренекле шәхесләр, «Татар сүзе»нә канат куйган Марат Әхмәтов та карады. Миңа калса, бу концертлар этәргеч биргәннәр. «Татар сүзе»ндә 2 ел жюри рәисе булдым һәм чын күңелемнән эшләдем. Алга таба башка кешеләр эшли икән, теләгем бер генә: нәтиҗәсе булсын.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ӘҢГӘМӘ ТУЛЫСЫНЧА VATANTAT.RU САЙТЫНДА

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА

ШУНДЫЙ ИНДЕ БЕЗ...

(Бәян)

< Дәвамы. Башы 15, 22, 29 сентябрь, 6, 20 октябрь саннарында

– Мирзамны тагын каядыр юлладың бугай, әткә, – диде ул, аның тавышында ризасызлык сизелә иде.

– Остаз! – дип төзәтте Галиб.

– Йә, Остаз диик. Сиңа мәгълүм ки, онытың маҗаралар белән мавыга. Канатам диме, һәр тишеккә борынын тыга.

– Мин аңа җитди йомыш куштым.

– Барыбыздан да яшерепме? Ичмасам шура әгъзалары белән киңәшер идең, Остаз!

– Сабыр, нәтиҗәсе турында ахырдан әйтелер. Кайчакта ялгыз гына уйлап эшләнгән эш өер белән хәл итүгә караганда отышлырак була.

– Бәлки, – диде Мангуш, килешкән төсле. – Синең абруең зур анысы. Ләкин ник соң син Мирзам белән барлык элемтә чараларын өздерттең, хәзер аның белән бары тик үзең генә аралашасың?! Ул бит – минем дә каным, минем бердәнбер улым! Үсмер чагында ук оныгыңны Җир белән бәйләдең, әткә! Ике аяклы адәмнәр төягән йөзләгән галим күзәтә, тот та шуларның берсен җибәр юкса! Ә син һаман Мирзамны утка ыргытасың!

– Оныкүзе риза, аңа Җир ошый!

– Картаясың, ахрысы, әткә! – дип пошынды Мангуш.

Галиб сискәнде. Хак, картая... Тиздән Кодрәт иясе хозурына күченер. Җиһанда бер генә мәхлукның да тышкы кабыгы мәңгелек түгел. Җан гына мәңгелек...

– Картайсам да үкенмим, – диде Остаз. – Алмашка син җитештең. Дәрәҗәң зур, хөрмәтең зур. Шура әгъзалары сиңа гына өмет баглый, улым. Мин моңа шат. Тик улым... – Остазның калын тавышы нечкәрде. – Җирне ташлама, үтенәм...

– Җир дип саташасың инде, әткә!

Галиб чытырдатып күзен йомды. Ул шулай тынычлана иде.

– Остаз, галимнәр унынчы буын суперкорабларны сыный. Синең әмерең нигезендә яңа планета өчен йөз очкыч ясала.

– Хуп, улым.

– Аны ничек дип атарбыз икән, Остаз?

– «Җәннәт почмагы» диярбез, Мангуш. Син әле ашыкмыйсыңмы? Моны миңа үләр алдыннан Әнсари бабаң сөйләп калдырды. – Ул кат-кат агарган сакалын сыпырды, әйтерсең сере иягенә төенләнгән дә, хәзер аны әкрен генә, кабаланмыйча гына чишәргә кирәк иде. – Ике йөз дә алтмыш алты ел элек безнең «тәлинкә», туфрак катламын тикшерергә дип, Сыер дигән татай авылының урман аланына төшә. Галим үзе белән биш яшьлек улын да ала. Малай корабта йоклап кала. Эшен төгәлләп кире килсә, бала юк! Галим ары карый, бире карый һәм күбәләкләр куып уйнаган малаен күрә. Ни гаҗәп, сабый өс киемнәрен салган, ялангач икән. Ул аны утырткычка кертеп утырта. Моңарчы тәрәзәчектә җемелдәгән йолдызларны саный-саный тыныч кына сәяхәт иткән малай шыңшып-көйсезләнеп бара. Кайткач кына аңлый әти кеше: улы Җир баласы белән алмашынган. Әйе, ул йөз-кыяфәте белән ике су тамчысы кебек үзенең малаена охшаган була, ләкин ятсынуы, беренче тапкыр күргәндәй уенчык роботларны әйләндереп-әйләндереп каравы «сата». Әгәр дә галим ялгышы турында шура әгъзаларына әйтсә, котылгысыз җәзага тарачагын белә. Ят баланы кабат аланга кайтарып, ә үзенең газизен табып хатасын төзәтергә ниятли ул. Тик өч очышта да «тәлинкә» ватыла. Атасы – Центавр Хуҗасы, билгеле, аның койрыгына баса. Фаш итеп, улын үтертмәс бит инде. «Бөек Кодрәт иясе шулай хәл кылгандыр, син, улым, беркемгә дә белгертмә, нарасыйны үз улың кебек тәрбиялә, гыйлем серләренә төшендер, бу бала – синең дәвамчың», – ди. Без, Мангуш...

Сүз бавы өзелде, баштанаяк зәңгәрсу тукымадан тегелгән киемгә төренгән кыз керде. Ул:

– Гафу үтенәм, Мангуш, сине шәкертләрең дәрескә көтә, – дигәч, Галиб сөенеп:

– Бар, улым, бар, – диде.

Хикмәтле сер сандыгын ачып, ни ота ул, йә? Ашыга, Галиб, ашыга. Картая, янәсе! Сиңа: «Фәлән хәтле генә яшисең», – дип белешмә язып тоттырганнармыни! Галиҗәнап билгеле гомер озынлыгын, ул гына белгели. Мөгаен, аның хикәяте җәлеп тә итмәгәндер, мәгәр Мангуш кызыксынса, тукта, моның азагы ничек бетәр икән дип, тагын аз гына тоткарланыр иде. Тоткарланды, хәер. Кисәткәндәй:

– Әткә, хыялый әсәрләр язып көлдермә, бала алмашу турындагы әкиятең сиңа чеметем генә дә дан өстәми, – диде. – Син – искиткеч талантлы галим, син бәһасез ачышларың белән Центавр тарихында тирән эз сыздың, – диде.

Галиб баягыдан да ныграк сөенде. Әлегә ышанмавы хәерлерәк. Әкиятнең чын икәнен исбатлар ул, исбатлар, онык кына исән-сау әйләнеп кайтсын...

–4–

Хәсән картның базары сыек иде. Ни бәрәңгесе, ни чөгендере сатылмаган, болай да балчыклы тауар, кояшта кибеп, «негр малайлары»на әйләнгән иде.

– Нигә тәңкә? – диде Мирзам, чиләкләр өстенә иелеп. Беләзектәге төймә чыелдамады.

Карт керфеге коелган шәрә күз кабагын күтәрмичә генә:

– Бушлай, ал, – диде.

Машина баскычына арт санын төрткән шофер кош төсле кулы белән кагына-кагына:

– Менә, менә! Ал, ди, имеш! Чүплеккә ташларга иренә,ызначит! Пычранма, хур җитәкчесе! Киттек! – дигәч кенә сатучы күзен ачты.

– Синең машинаңда ящик тулы агу, Кафил бәндәсе. Нәсел корытучы син!

– Синдә һаман бер такмак инде, агу да агу, имеш!

Мирзам чиләкләрне берәм-берәм капчыкка бушатты.

– Кафил агай, әрҗәгә куйыйк әле.

– Үлсәк үләбез, зато ашап үләбез, бабай! – диде шофер, ямьсез ырҗаеп.

– Ух, нәсел корытучы дошман! – Хәсән карт таягы белән селтәнгән иде, Кафил кабинасына атылды:

– Сукса, башыңны яра, көчле, шайтан алгыры!

Шәкүрә карчык:

– Базар катыннары ир-атка мыскыллап шакшы әйбер тутыра шул. Син дә, күзле букән, капчыгыңа нәмә аткарганнарын карамадыңмыни, җә? – дип, базарын, Мирзамның бергә өеп тирги-тирги яшелчәләрне сулы ләгәнгә томырды. – Җебесеннәр!

Мирзам берни дә аңлатмады, чөнки файдасыз иде. Аннары, вакыт дигәнең чаптырып арттан куа, аның һәр минуты исәптә, җәелеп-таралып йөрсәң, вакыт үзе үк төп башына утыртачак иде. Клубта да кымтыраталар, Фәзилә әнә озак килми дип мыгырданадыр инде.

Егет «Мәдәният йорты»на юлны кыскартам дип, тыкрыктан гына киткән иде, өченче бакчада алты аяклы үрмәкүчнең җир сөргәнен күреп, шул якка борылды. Клуб качмас ла! Гаҗәпләнмәде ул, мондый батрак-роботлар Центавр мәмләкәтендә гадәти нәрсә санала, ә Җирдә бу гайре табигый күренеш иде. Сукадан тракторга әле кайчан гына күчкәннәр! Авыл гына димә икән, кул хезмәтен ничек җиңеләйтәләр. Димәк, монда башлы татай гаиләсе яши. Чыпчык оясында – чыпчык, бөркет оясында бөркет үсә, бәлки нәкъ шушы гаиләдә яңа планетага лаек егет-кызлар тәрбияләнгәндер?

Аңа каршы дөя кебек аркасына йөк аскан кызыл косынкалы кыз белән тәлпәк кигән егет килә иде, Мирзам сынап та, өметләнеп тә аларга карады. Икесе дә чибәр, икесе дә ачык йөзле. Татайлармы икән? Их, беләзектәге иң кирәкле тишекнең төймәсе куптарылган! Шуңа басса, «дөя»ләрнең кемнәр икәнен секунд эчендә ачыклар иде дә... Остаз бабасы: «Интуиция – иң шәп ярдәмчең», – диде шул.

Лач-лоч сагыз чәйнәгән яшьләр гүя былтыргы танышын очратты, икесе дә беравыздан урам яңгыратып сәламләде:

– Исәнмесез-саумысыз, абый?! – Үзләренең теле телгә йокмады. – Сыерда сине беренче тапкыр күрәбез. Кунаккамы?

– Клубка эшкә билгеләделәр, – диде Мирзам. – Сәнгать җитәкчесе мин.

– Оһо, кич белән дискотекада тыпырдыйбыз икән!

Кыз бию хәрәкәтләре ясады.

– Абый, абый, бездә Америка поп йолдызы Николь Кеаның дискы әллә ничә. Хәзер үк биримме? Музыкасы маймыл кебек сикертә! – дип авыз ерган егеткә Мирзам кырыс кына:

– Татай көйләренә биерсез, яме? – диде.

Әмма аның дорфалыгы һич кенә дә яшьләрнең кәефен бозмады.

Кыз:

– Ярый, абый, ярый, без татай моңнарын да үлеп яратабыз, – дигәч, Мирзамның нокта хәтле генә өмете зурая-зурая тәвә йомыркасы кебек булды. Бу яшь парны күз уңыннан ычкындырмаска кирәк! Оядә беренче мая бар! Сокланып туймаслык, саф татайча ничек матур сөйләшәләр!

Дәвамы бар >

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына **«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»** газетасына языл

П2435 >>
571 сум 98 тиен
(җомга)

П2409 >>
1255 сум 86 тиен
(сиш., чәрш., җомга)

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана. 2 ноябрьдә уйнатылачак бүләк – **10 кг он**

Бу атна җиңүчесе – Тәтеш районы Олы Тархан авылында яшәүче Шайнурова Фирая. Котлыйбыз һәм элемтәгә чыгуыгызны үтенәбез!

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!
Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Реклама 16+

Әз-мәз мәзәк

– Хатын-кыз букчасында нәрсә юк?
– Урын.

***

Бу атнаны сыра фестивалендә куркыныч хәл килеп чыкты. Көтмәгәндә гаражга хатын килеп керде.

***

Иминият компаниясенә полис алырга килсәң, син – клиент. Компенсация сорап килсәң – мошенник.

***

«Ура! Әни кайтты!» – дип оныкларын да уздырып, алдан дәү әни чаба иде.

***

– Шәп татуировка!
– Варикоз бу.

***

Хезмәт ул маймылдан кеше ясаган. Хезмәт үз эшен башкарды. Хәзер без – кешеләр. Эшләмәсәк тә була.



Сканворд җаваплары

Горизонталь: тоз, шалкан, мишәр, ирек, мат, шоу, ике, улы, тар, фанат, ми, аз, до, еш, җеназа, Шекли, Ра, Враз, Семык, Ан, Дивана, лимонад, шук, касә, сер, Ной, Лори, ас, Лев, бур, Ту, дә, Болак, мәми, криз.

Вертикаль: җитмеш, ләм, Ом, Каишев, икеле, зикер, Крамаров, Ланос, Ди, шәм, жиз, Нәҗибә, ара, да, Туфан, Сид, РБК, ки, Ларзарев, Ор, аршын, машина, Ли, Нео, адарыну, остаз, Кусто, Акакий, ук.

Беләсең килсә...

1 Экодук нәрсә өчен файдаланыла?
а) агачта радиация фонын тикшерү өчен;
б) кыргый хайваннарны трасса аша чыгару өчен;
в) экологиягә зыян китермичә зыянлы матдәләрне саклау өчен.

2 ВАЗ-2107 модель «Жигули» ничәнче елга кадәр җитештерелде?
а) 2007;
б) 2010;
в) 2012.

3 Дөньядагы бөтен саннарны бер-берсенә тапкырласаң, нинди сан килеп чыгачак?
а) триллиард;
б) ноль;
в) чиксез сан.

4 Аяз Гыйләҗев исемен кайсы театр йөртә?
а) Чаллы театры;
б) Әлмәт театры;
в) Минзәлә театры.

Җаваплар: 1.б); 2.в); 3.б); 4.а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13580 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 346

РЕДАКЦИЯ һәМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – **газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булырак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+